СИШӘМБЕ
16 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 88 (5888)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: *Казан, Матбугат йорты.* ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм массовый бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 8—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ ҺӘМ БАШЛАНГЫЧ ПАРТОЕШМАЛАРНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

Партиянең тарихи XVIII нче съезды карары буенча колхоз, совхоз һәм МТС лар янындагы башлангыч партоешмаларга администрациянең эшенә контроль функциясе бирелде. Моның нәтиҗәсендә башлангыч оешмаларның роле тагын да үсте, аларның колхоз, совхоз һәм МТС производствосына җитәкчелеге тагын да көчәйде, бу эштә җаваплылыклары үсте. Бик күп урыннарда башлангыч партоешмалар политик-масса эшләрен хуҗалык бурычлары белән бергә бәйләп алып баруның гүзәл үрнәкләрен күрсәттеләр һәм күрсәтәләр.

Партиянең колхозлар янындагы башлангыч оешмалары контроль ясау хокукыннан киң рәвештә файдаланып, хуҗалык бурычларын хәл кылырга, дәүләт планнарын үрнәк итеп үтәү өчен көрәшергә яхшы итеп өйрәнделәр.

Мисальгә Чистай районының Вахитов исмендәге колхозы, Этнә районының Киров исмендәге колхозы янындагы башлангыч партоешмаларны алырга мөмкин. Бу оешмалар колхоз правлениеләренең эшенә контроль ясау функциясен, җитәкчелек итү стилен чын мәгънәсе белән үзләштергәннәр. Алар партҗыелышларда колхоз правлениеләре председательләренең язгы чәчүгә хәзерлек буенча докладларын тыңлаганнар, билгеле бер вакыттан соң ул карарның үтәлешен тикшергәннәр, партия членнарының һәм кандидатларының күпчелеге производствода эшлиләр һәм күренекле эш үрнәкләре күрсәтәләр. Вахитов колхозындагы коммунистлар һәм комсомолецлар язгы чәчү вактында производствоның иң әһәмиятле тармакларында эшләячәкләр. Мәсәлән, Миңлехан Вәлиев, Исхак Усманов иптәшләр чәчү машинасында, Әхмәт Мингулов, Гаяз Вәлиев, Салих Фасхутдинов һәм Әхтәм Нигматуллин иптәшләр культиваторда, Вәли Сафиуллин иптәш тырмалау эшендә эшләячәкләр. Алар эш төрләре буенча билгеләнгән норманы арттырып үтәү турында йөкләмәләр алып социалистик ярышка чыктылар. Бу колхозлар язгы чәчүне тулы хәзерлек белән каршылыйлар.

Партия оешмасының производство эшенә якыннан контроль ясавы, масса-политик эшне җәелдерүе, хезмәт дисциплинасын ныгытуда, социалистик ярышны җәелдерүдә колхоз правлениесенә якыннан ярдәм итүе нәтиҗәсендә Киров исмендәге колхоз 1939 нчы елны үзенең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен вактында тулысынча үтәгән, терлекчелекне үстерү планын атлар буенча 103 процент, сыерлар буенча 110 процент, сарыклар буенча 166 процент итеп үтәгән. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашып, беренче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнгән һәм күргәзмәдә быел да катнашуга кандидат булып тора.

Колхоз правлениеләре эшенә контроль ясауны, җитәкчелекне яхшы һәм дөрес итеп оештыру башлангыч оешмаларны күпләп китерергә мөмкин. Ләкин шундыйлар белән бер рәттән партия уставының 61 нче параграфын тиешенчә аңламаган, колхоз производствосына җитәкчелекне юлга салмаган башлангыч оешмалар да бар әле. Этнә районы „Электросталь“ колхозы янындагы башлангыч партоешмасы (секретаре иптәш Хәкимҗанов) 1939 нчы елның көзеннән 1940 нчы елның март аена кадәр булган вакыт эчендә партия җыелышларында колхоз производствосына кагылышлы бер мәсьәлә дә тикшермәгән. Гомумән бу оешма хуҗалыкка җитәкчелек эше белән аз шөгыльләнә. Шуның нәтиҗәсендә бу колхозда кышкы агротехника чаралары өзелгән, хезмәтне звенолап оештыру эше, колхозчылар арасында масса-аңлату эшләре тиешле дәрәҗәдә куелмаган, терлекчелекне үстерү планы үтәлмәгән. Шунсы гаҗәп, бу оешмада ВКП(б) райкомы инструкторы иптәш Ваһапов соңгы 5—6 ай эчендә 7 тапкыр булган, ләкин партоешмага һәм аның секретарена колхоз производствосына җитәкчелек итү эшендә бер төрле ярдәм күрсәтмәгән, ул мәсьәләләрне бөтенләй игътибардан читтә калдырган.

Чәчүне максималь кыска срокта югары сыйфат белән үткәрү һәм өч республика ярышында алган йөкләмәләрне большевикларча үтәү — колхозлар, совхозлар янындагы партоешмалар һәм авыл райкомнары алдында торган иң зур бурычларның берсе әнә шул. Бу мөһим бурычны үтәү барлык колхозларга, МТС ларга оператив җитәкчелекне тәэмин иткәндә генә мөмкин.

Партиянең колхоз, совхоз һәм МТС лары янындагы оешмалары язгы чәчү вактында колхоз правлениесенең, МТС һәм совхоз дирекциясенең эшенә контроль ясауны, аларга ярдәм итүне, колхозчылар, МТС һәм совхоз эшчеләре арасында политик-масса эшләрен яхшы итеп оештыруны, коммунистларның, комсомолецларның производствода авангардлыкларын тәэмин итүне, алдынгылар тәҗрибәләрен уртаклашуны, артта калучыларга [illegible] практик ярдәм оештыруны игътибар үзәгенә куярга тиеш.

Чәчүнең барышын тикшерү һәм алдынгы тәҗрибәне уртаклашу өчен һәр көнне эштән соң 10—15 минутлык производство киңәшмәләре үткәрү, бригада һәм колхоз стена газеталарын чыгару кирәк.

Югары иген уңышы яулап алу өчен көчле резервларның берсе — илебездә, шул исәптән безнең республикабызда, киң колач алган йөзпотлылар хәрәкәте. Югары уңыш өчен көрәшүне оештыру, чәчүне оешкан рәвештә үткәрү өчен көрәшү партиянең башлангыч оешмаларының иң әһәмиятле хәл иткеч бурычларыннан берсе. Язгы чәчү партиянең авылдагы башлангыч оешмасы өчен зур политик сынау. Бу сынау отличнога үткәрелергә тиеш һәм үткәрелер.

ТАССның ЮККА ЧЫГАРУЫ

Англиянең Рейтер агентлыгы, „Афтонбладет“ газетасының Каунастагы хәбәрчесенең хәбәренә таянып, Германиянең Москвадагы илчесенең Германия гаскәрләрен Норвегиягә китерү өчен Мурманскидан һәм Мурманск тимер юлыннан файдаланырга Германиягә рөхсәт бирү турында иптәш Молотовка мөраҗәгат иткәнлеге һәм Совет хөкүмәтенең бу үтенечне кире какканлыгы турында хәбәр тарата.

Рейтерның бу хәбәренең дөрес түгеллеген, чөнки Германиянең мондый үтенеч белән СССР га мөраҗәгат итмәгәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

Чикне демаркацияләү буенча Совет—Финляндия катнаш комиссиясенең эше турында

Финляндия республикасы белән солых договорына кул куелгач та, солых договорының икенче статьясенә туры китереп, СССР белән Финляндиянең үзәк катнаш чик буе комиссиясе төзелгән иде.

Совет хөкүмәте югарыда күрсәтелгән катнаш чик буе комиссиясенә делегацияне түбәндәге составта билгеләде: комдив иптәш А. М. Василевский (Совет делегациясенең председателе), комдив иптәш В. Д. Иванов, полковник иптәш А. С. Ивойлов һәм Наркоминдел вәкиле иптәш И. В. Маевский.

Финляндия хөкүмәте үз тарафыннан делегацияне түбәндәге составта билгеләде: профессор Бонсдорф, элекке министр Хаксель, генерал Аппельгрен, полковник Аминоф.

СССР белән Финляндиянең шушы көннәрдә генә Выборг шәһәрендә җыелган үзәк катнаш чик буе комиссиясе, үзара тулысынча аңлашу шартларында, Совет—Финляндия дәүләт чиген төгәл итеп билгеләде, бу чикнең тулы аңлатмасын төзеде һәм аны демаркацияләү тәртибен билгеләде.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

ЧӘЧҮ БАШЛАНДЫ

БАУЛЫ, 15 апрель. (Телефон буенча). Беренче көн инде районның күпчелек колхозларында тырмалау, язгы сөрү һәм культивацияләү эшләре бара. Кичә Тат. Томбарлы һәм Баулы авылы колхозлары бодай чәчүгә, Ленин исмендәге колхоз солы чәчүгә керештеләр.

Бүген районның барлык колхозлары да массовый төстә кыр эшләренә чыктылар.

Поляков.

БАЛТАЧ, 14 апрель. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). Бүген „Кызыл Тау“ колхозы 13 гектар, „Днепр“ колхозы 7 гектар клевер чәчте.

„Кызыл Ямьләр“ колхозында язгы чәчү участокларындагы амбарларга ташу эшенә керештеләр.

ЗАИНСКИЙ, 15 апрель. (Телефон буенча). Районда язгы чәчү эшләре массовый төс ала. 12 нче апрельдә „Вторая Пятилетка“ колхозы 4 гектар, „Ворошиловец“ колхозы 3 гектар, „Красная Заря“ колхозы 4 гектар солы чәчтеләр. Молотов исмендәге колхоз 20 гектар, „Югары Чишмә“ колхозы 20 гектар, „Ворошиловец“ колхозы 24 гектар һәм „Завет Ильича“ колхозы 12 гектар җир сөрделәр.

„Кызыл Октябрь“ (Акшар авылы) колхозында туңга сөрелгән 44 гектар җир тырмаланды һәм 24 гектар җир культивацияләнде. Культивациядә эшләүче Ханҗәминев һәм Яхин иптәшләр норманы беренче көнне үк 105 процент итеп үтәделәр. Тырмалауда Мардашин һәм Кашапов иптәшләр дә норманы арттырып үтиләр.

Районның Чыбыклы МТС ы тракторлар белән эшкә керешә. „Красная Заря“ колхозында тракторчылар Розанов һәм Доронин иптәшләр эшкә чыкканның беренче көнендә үк уңышлы нәтиҗәләр бирделәр. Алар сменада 8 гектар урынына 12 гектар сөрделәр. „Кызыл Октябрь“ колхозы (Югары Нәлим авыллы) НАТИ тракторында эшләүчеләрдән Ганиев һәм Төхфәтуллин иптәшләр дә норманы арттырып үтиләр.

М. Шумутов.

БОНДЮГ районының „Восход“ һәм „Труженик“ колхозлары районда беренче булып чәчүгә чыктылар. „Восход“ колхозы 5 гектар клевер һәм 2 гектар бодай чәчте. „Труженик“ колхозында 18 гектар чирәм сөрделе.

Бондюг машина-трактор станциясе (директоры иптәш Гагарин) язгы чәчүне хәзерлексез каршы алды. Бу МТС та 50 трактордан 12 тракторга ремонт ясалмаган.

Тәкәнеш районы колхозлары клевер чәчә башладылар. „Коммунар“ колхозы 65 гектар, „Новая Жизнь“ колхозы 35 гектар һәм „Красный Октябрь“ колхозы 5 гектар клевер чәчтеләр.

Чәчү орлыкларын яровизацияләү эше дә башланды. Районда 400 гектар җиргә утырту өчен бәрәңге һәм 200 гектар җиргә чәчү өчен вика яровизацияләүгә салынды.

Биектау районының Вахитов исмендәге колхозы 50 гектар клевер чәчте. „Кызыл Байрак“ колхозында 20 гектар һәм Марфин исмендәге колхозда 15 гектар клевер чәчелде.

Чистай районының „Урожай“ һәм „Мәгариф“ колхозларында 15 нче апрельдә язгы сөрү эшенә керештеләр.

Андреев исмендәге колхозда туңга сөрелгән җирне тырмаладылар. Ленин исмендәге, „Власть Советов“ h. б. колхозлар да әлеге участокларда язгы сөрү эшенә керештеләр.

Лаеш районының кайбер колхозларында язгы кыр эшләре башланды. „Беренче Май“ колхозында 6 гектар, „Буденновец“ колхозы 6 гектар мәйданда клевер чәчтеләр. „Яңа Алан“ колхозында язгы сөрү эшенә керештеләр.

14 нче апрельдән „Красное Поле“, „Красное Полянка“ „Камский“ һәм „10 лет Динамо“ колхозларында да язгы сөрү һәм культивацияләү эшенә керештеләр.



Лаеш районы, „Красный Дол“ колхозы бригадиры А. Трифонов һәм бригада членнары А. Сычев һәм М. Медведев иптәшләр уҗымнарның торышын карыйлар. С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Орлык белән ярдәмләшү

Арча районында чәчүлек орлыклары үзләреннән арткан колхозлар 700 центнер орлыкны башка колхозларга бирделәр. Колхозара ярдәмләшү районара ярдәмләшүгә әйләнде. „Байкал“ колхозы Биләр районы колхозларына 420 центнер бодай, 130 центнер солы бирде һәм бу орлыкны Заготзерно пунктына тапшырды. „Кызыл Сабан“ колхозы да шулай ук Биләр районы колхозларына 75 центнер бодай һәм 14 центнер солы бирде.

Н. Хәйруллин.

Этнә районының күп кенә колхозлары башка районнарның чәчү орлыклары җитәрлек булмаган колхозларына бурычка 5.270 центнер орлык бирделәр. „Кызыл Шахтер“, „Таң Нур“ һәм башка күп кенә колхозлар бу орлыкларны Заготзерно пунктына озату эшен төгәлләделәр инде.

Кузәев.

Кызыл Юл районының „Шурабаш“ колхозы, гомуми җыелыш карары буенча, колхозның запас орлык фондыннан Мирҗән колхозына 250 центнер, башка район колхозларына 280 центнер чәчүлек орлык бирде. Карл Маркс исмендәге колхоз да Калинин исмендәге колхозга 550 центнер орлык биреп ярдәм итте.

С. Гали.

ЧӘЧҮЛЕК ОРЛЫКНЫ ҮЗЛӘРЕННӘН ТАБАЛАР

Заинский районында чәчүлек орлыкны урыннан эзләп табу турындагы мәсьәлә буенча колхозчыларның җыелышлары үткәрелә. Районда ара ярдәмләшү тәртибендә 1.100 центнер чәчүлек орлык җыелды инде. Аерым колхозчылар зур ярдәм күрсәтәләр. „Красная Заря“ колхозы члены Алексей Будрин бурычка 10 центнер, Иван Никитин 8 центнер һәм Александр Никитин 6 центнер чәчүлек орлык бирделәр. Бу колхозның членнары барлыгы 60 центнер орлык бирделәр.

(ТатТАСС).

Зур күтәренкелек белән

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын Юдино районы колхозчылары тирәнтен канәгатьләнү һәм зур күтәренкелек белән каршы алдылар.

Бу карар басылган газеталар килеп җитү белән күп колхозларда колхозчыларның гомуми җыелышлары үткәрелде. Җыелышларда карар яхшылап өйрәнелде.

„Красный Дол“ колхозы членнарының гомуми җыелышында чыгып сөйләгән колхозчы иптәш Евсеев болай диде:

— Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы тарафыннан кабул ителгән карар колхозлар һәм колхозчылар турында Сталинчыл кайгыртучанлыкның никадәр көчле булуын күрсәтүче яңа факт булып тора. Бу карар колхоз строен тагын да ныгытуга һәм колхозчыларның таза тормышлылыгын тагын да күтәрүгә юнәлдерелгән. Бу карар алдынгыларны яхшырак эшләргә дәртләндерә һәм арттагыларда алга таба бару омтылышын тудыра.

Җыелыш колхозда терлекчелекне үстерү һәм колхоз җирләреннән дөрес итеп файдалануны оештыру буенча правление алдына конкрет тәкъдимнәр куйды һәм бу турыда план төзәргә кушты.

РЕДАКЦИЯДӘН

Газетабызның 14 нче апрель номерында урнаштырылган „Колхозларның һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары турында“ ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарының 6 нчы пунктының, икенче юлындагы „колхозлар“ дигән сүзне „колхозчылар“ дип укырга кирәк.

Чәчүне хәзерлексез каршылыйлар

Балтач районы колхозларында массовый күләмдә язгы кыр эшләренә керешергә 3—4 көн калды. Кайбер колхозлар клевер чәчә дә башладылар инде. Ләкин районның күп колхозлары язгы чәчүгә хәзер түгел.

Җитешмәгән орлыкны урында табу эше оештырылмаган. Дәүләт бирер әле, дип иждивенчелек настроениесе дә бар.

Булган чәчү орлыкларын да тиешле кондициягә җиткерүгә һәм саклауга кайбер колхозларда бөтенләй әһәмият бирелми. „Кызыл Көч“ колхозында (председателе иптәш Фәйзерахманов), чәчү орлыгы җитешмәүгә карамастан, 74 центнер орлыкны колхозның башка кирәкләренә тотканнар. „Яңа Тормыш“ колхозында (председателе иптәш Әхмәдуллин) орлыклар тиешле кондициядә түгел. Бу колхозда орлык амбарларының түбәләре тишек. Орлыкка яңгыр үтә. Ленин исмендәге колхозда орлыкларны тазарту эшенә хәзергә кадәр керешми торганнар.

Язгы чәчү эшләренең 50 проценты бу районда атлар көче белән башкарылырга тиеш. Ләкин районда атларны чәчү эшенә хәзерләү онтылган эш булып тора.

Х. Галләмов.

ССР Союзының Зур Театрында В. В. Маяковский истәлегенә багышланган тантаналы - кайгылы утырыш

ССР Союзының Зур Театрында тамаша залы совет язучылары белән, артистлар белән, галимнәр белән Москва заводларының һәм фабрикаларының стахановчылары, Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары белән, партия һәм совет работниклары белән тулган. Шулар арасында—Советлар Союзы Геройлары, СССР һәм РСФСР Верховный Советларының депутатлары, орденлылар, илебезнең атаклы кешеләре.

Сәхнәдә—Владимир Владимирович Маяковскийның чәчәкләр белән урап алынган зур портреты янында почетный караул. Портрет турысында, югарыда—илебезнең һәрбер хезмәт иясенә бик таныш булган сүзләр: „Маяковский безнең Совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре булды һәм шулай булып кала“ (Сталин).

Председательлек итүче—шагыйрь **Н. Асеев** Совет Язучылары Союзы исменнән һәм В. В. Маяковскийның истәлеген мәңгеләштерү комитеты исменнән тантаналы - кайгылы җыелышны ачык дип игълан итә. Доклад ясау өчен язучы **А. Фадеевка** сүз бирелә.

Иптәш Фадеев бөек Совет шагыйренең иҗад юлы турында, Совет әдәбиятында аның тоткан урны һәм әһәмияте турында сөйли.

— Моннан 10 ел элек язылганнарның күбесе инде искерде, ләкин Маяковский шигырьләренең ялкынлы көче сүнмәде. Маяковскийның поэзиясе массаның аңына торган саен тирәнтен керә бара.

— Маяковский үзенең сүзләре белән эшчеләр сыйныфының барлык һәм һәр төрле дошманнарын, халкыбызның дошманнарын фаш итте. Ак гвардияче калдыклардан алып троцкичы-бухаринчы кабахәтләргә кадәр, иске дөньядан калган барлык әшәкеләр безнең эпохабызның иң яхшы, иң талантлы шагыйрен үлем дошманы итеп күрделәр. Дошманнар Маяковскийны эзәрлеклиделәр, кыстылар, аны әдәбияттан аерырга тырыштылар. Алар Маяковскийның Ленин—Сталин партиясенә һәм Совет хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгән булуын гафу итә алмадылар. Ә бу бирелгәнлек чыннан да чиксез иде. Маяковский, мин партия члены булмасам да партиянең карарларын үзем өчен мәҗбүри дип саныйм дигән сүзләрне берничә тапкырлар әйтте.

— Владимир Маяковский үзенең бөтен тормышын коммунизм өчен көрәшкә бирде. Ул үзенең эше белән, үзенең армый-талмый иҗад итүе белән, эшчеләр сыйныфы эшенә бөтенләйгә бирелгән булуы белән иптәш Сталин тарафыннан аңа бирелгән югары бәяне яулап алды. Иптәш Сталин Маяковскийны Совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре дип атады.

Иптәш Фадеев докладыннан соң кардәш республикаларның шагыйрьләре Маяковскийның СССР дагы халыкларның телләренә тәрҗемә ителгән иң яхшы шигырьләрен укыдылар.

ВКП(б) Үзәк Комитетына—иптәш Сталинга һәм Совет хөкүмәтенә—иптәш Молотовка котлау җибәрергә дигән тәкъдим гаять зур күтәренкелек белән каршы алынды. Котлауның **В. Вишневский** тарафыннан укылган тексты озакка сузылган кул чабулар белән берничә тапкырлар өзелеп торды. Җыелышта катнашучылар большевиклар партиясе Үзәк Комитеты, Совет хөкүмәте, бөек Сталин һәм иптәш Молотов хөрмәтенә көчле алкышлар ясадылар.

Җыелыштан соң концерт булды.

КАЗАНДА В. В. МАЯКОВСКИЙ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ҖЫЕЛЫШ

14 нче апрельдә, Менжинский исмендәге клубта, революциянең бөек шагыйре В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу көненә багышлап шәһәр күләмендә гомуми җыелыш булды.

Шагыйрьнең тормышы һәм иҗады турында татар шагыйре иптәш Г. Кутуй доклад ясады. Ул үзенең ачык һәм тулы докладында, Маяковскийның иҗад юлын, аның шигырьләренең замандашларына гаять зур йогынтысын, аның патриотизмын, сыйнфи дошманнарга каршы көрәштә сизгер булырга чакыруын ачык итеп күрсәтте.

Докладтан соң әдәби бүлек булды.

Татар шагыйрьләре Хәсән Туфан, Әхмәт Исхак, Гадел Кутуй, шагыйрь Колесников һәм башкалар Маяковскийның рус телендәге әсәрләрен һәм татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләрен, шулай ук Маяковскийга багышланган шигырьләрне укыдылар.

Концертта Татарстанның халык артисткасы Асия Измайлова, шулай ук Татар Дәүләт Опера театры солистлары Рудаков һәм Пустоветов иптәшләрнең чыгышлары булды.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

БЕЗНЕҢ ЯЧЕЙКА НИЧЕК ЭШЛИ

Этнә районы, Киров исемендәге колхозда дингә каршы пропаганда эше соңгы вакытта шактый яхшырды. Бу эштә Сугышчан Аллаcызлар Союзы ячейкасы зур инициатива күрсәтә. Ячейка үзенең агитация һәм пропаганда эшен дингә каршы дәресләр буенча беседалар, докладлар һәм лекцияләр уздыру тәртибендә алып бара.

Шушы дәреслектән чыгып, „Коммунизм һәм дин“, „Фән һәм дин“, „Дөньяның төзелеше“, „Җирдә тереклекнең килеп чыгуы һәм үсүе“ дигән темаларда докладлар һәм лекцияләр уздырылды. Аларда 600 дән артык колхозчы катнашты. Шул ук вакытта без, аерым мәсьәләләр буенча беседалар һәм кычкырып газета уку лар да оештырабыз.

Ячейка укытучылар белән якын элемтә тота. Алар лекцияләр уку, докладлар ясауда безгә зур ярдәм күрсәтәләр. 9 нчы апрельдә „Кешенең килеп чыгуы“ дигән темага оештырылган лекцияне укытучы иптәш Шагалиев укыды. Лекциядә 59 кеше тыңлады. Лекция соңында алар бик күп сораулар бирделәр һәм кабатлап булса да, „Җирдә тереклекнең килеп чыгуы“ турында тагын лекция тыңларга теләкләрен белдерделәр. Мондый лекцияләрне уздырганнан соң һәр вакыт диярлек оешмада членнар саны арта бара. Бу юлы да 8 колхозчы Сугышчан Аллаcызлар Союзына член итеп алуны сорап гариза бирделәр. Хәзер безнең оешмада членнар саны 51 гә җитте. 72 яшендәге Гариф Манапов, 79 яшендәге Гали бабайлар һәм башкалар оешмада актив эш алып баралар. Шуңа күрә дә безнең ячейка аллаcызларның Бөтенсоюз ярышында алдынгылар сафына чыкты һәм почет грамотасы белән бүләкләнде.

Киров исемендәге колхозда дингә каршы, иске гореф-гадәтләргә каршы пропаганда алып бару югары иген уңышы алу өчен көрәш белән нык бәйләп алып барыла. Колхозның алдынгы стахановчылары—безнең ячейканың актив агитаторлары да. Алар фән кушканча эшләргә кирәклекне һәм бары тик фән кушканча эшләгәндә генә югары иген уңышы алырга мөмкин икәнлекне үзләренең эш үрнәкләрендә ачык күрсәтәләр. Менә шуңа күрә дә, безнең Киров исемендәге колхоз, быелгы язгы кыр эшләрен һәр яктан тулы әзерлек белән каршылый.

Абдулла Сибгатуллин.

Сугышчан Аллаcызлар Союзының Этнә авыл ячейкасы секретаре.

Культура сараеның уку залында. Россельмаш: Ленин исемендәге завод инженеры иптәш А. Фаизов ВКП(б) тарихы буенча материаллар карый.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Оборона эшенә игтибар көчәйтелергә тиеш

СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясе 1940 нчы елгы дәүләт бюджетыннан оборона эшенә 57 миллиард сум акча билгеләде. Бу факт үзе генә дә безнең партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан илебездә оборона эшләрен көчәйтүгә никадәр зур игтибар бирелгәнлекне ачык күрсәтә.

Ләкин шуңа да карамастан, кайбер партоешмалар бу мәсьәләгә бәя биреп җиткермиләр, массовый оборона оешмаларына тиешенчә җитәкчелек һәм ныклы булышлык күрсәтмиләр. Мисаль өчен Серго Орджоникидзе исемендәге завод парткомын (секретаре иптәш Заброченко) күрсәтергә мөмкин.

Партком массовый оборона оешмасы тирәсенә коммунистларның игтибарын туплау һәм оборона значокларына нормалар тапшыруда аларның алдынгылык рольләрен тәэмин итү өчен тиешенчә көрәшмәгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бик күп коммунистлар бу мөһим эштән бөтенләй читтә торалар. Моны раслау өчен оешмадагы коммунистларның бары тик 5,5 проценты гына Осоавиахимда член булып торуларын күрсәтү дә җитә.

Партком Осоавиахим оешмасының җитәкчелеген ныгыту мәсьәләсе белән дә начар шөгылләнгән. Бу елның 3 ае эчендә Осоавиахим советының председателе 3 тапкыр алмашыну моңа ачык мисаль була ала.

Партком тарафыннан массовый оборона эшенә тиешле җитәкчелек булмау нәтиҗәсендә заводта оборона эшләренең торышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, заводта күп кенә оборона түгәрәкләре оештырылган. Ләкин аларның берсендә дә занятиеләр регуляр рәвештә үткәрелмиләр. Шуның аркасында Осоавиахим оешмалары тарафыннан быел завод күләмендә бер генә значкист та хәзерләп чыгарылмаган.

Осоавиахим оешмасында оборона инвентарьларына саксыз караш хөкем сөрә. Әгәр дә узган елны оешманың 115 противогазы булса, хәзер ул бары тик 30 гына калган.

Овчинников.

Бер артельнең комсомолецлары

„Металлист“ кустарь-промысло артеле (Чаллы шәһәре) яшьләре комсомол оешмасы производствода зур инициатива күрсәтә. Әгәр күптән түгел комсомолецлар күбрәк союзның эчке мәсьәләләре белән генә шөгылләнгән булсалар, хәзер алар производствога якын торып, стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итәләр, үзләре дә стахановча эшлиләр. Комсомолецлар хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрүдә яхшы үрнәкләр бирәләр. Мәсәлән, стахановчы комсомолец иптәш П. Семенов март ае заданиесен 210 процент итеп үтәде һәм хәзер дә темпны киметми. Комсомолецлардан С. Столяров үзенең көнлек заданиесен 236 процент итеп, В. Макарычев 250 процент итеп һәм А. Реутов 160 процент итеп үтиләр. Артельдә эш нормасын үтәмәүче бер комсомолец та юк. Комсомолецлар үзара ярышалар һәм артта калучы эшчеләргә алдынгылар сафына басуда ярдәм итәләр.

Артель беренче квартал планын 146 процентка үтәде. Безнең артельнең коллективы Татарстан АССР ның XX еллыгына 6 айлык планны срогыннан элек үтәргә йөкләмә алды.

Комсомол оешмасының инициативасы белән цехларда беседалар, кычкырып газета укулар, социалистик ярыш договорларының үтәлешен тикшерүләр һәм киңәшмәләр системалы рәвештә үткәрелеп тора. Бу киңәшмәләрдә кимчелекләр ачылалар һәм аларны төзәтү чаралары күрсәтелә.

Комсомол оешмасы массовый оборона эшен дә көчәйтте. Март аенда гына да артельнең яшь эшчеләреннән 20 кеше ПВХО значогына нормалар тапшырды.

В. Корноухов.

„Металлист“ артеле янындагы комсомол комитеты секретаре.

СЕКРЕТАРЬЛАР СЕМИНАРЫ

ВКП(б) ның Кукмара райкомы 5 нче апрельдән 9 ына кадәр башлангыч партоешмаларның яңа сайланган секретарьларының, аларның урынбасарларының һәм кандидатлар группалары парторгларының семинарын үткәрде. Семинарга катнашучылар партия хуҗалыгын алып бару, партия пропагандасына җитәкчелек итү һәм җыелышларны оештыру мәсьәләләре белән таныштылар һәм халыкара хәл турында доклад тыңладылар. (ТатТАСС).

Барлык комсомолецларның да үз өстендә эшләүләренә ирешергә

Беренче Май районындагы комсомолецларның шактый өлеше партия тарихын үзлекләреннән өйрәнү өстендә тырышып эшлиләр. Башлангыч оешмалар тарафыннан бу эшкә ныклы игтибар ителгән урыннарда комсомолецлар теоретик белемне үзләштерүдә яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр. Мәсәлән, район советы башкарма комитетындагы комсомолецлар „Кыскача курс“ның аерым бүлекләрен өйрәнгәндә һәрбер бүлек буенча алдан хәзерләнеп иптәшләрчә беседалар уздыралар. Анда бик күп мәсьәләләрне бергәләп аңлашалар. Бу оешма членнарыннан Сотников, Кузьмин, Архипова, Гыйрфанов һәм башка иптәшләр „Кыскача курс“ның VII нче бүлеген укып конспект төзеделәр инде.

Комсомолец иптәш Е. Храмов партия тарихының XII бүлеген дә өйрәнеп конспект төзеде. Хәзер ул партия тарихын беренче чыганаклар буенча өйрәнә башлады. Аерым алганда ул, Лениннең „Нәрсә эшләргә“, „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы“, „Аграр мәсьәләләр“ дигән әсәрләрен укыды инде.

„Свобода“ колхозындагы комсомолецлардан Марков һәм Гаврилов иптәшләр хәзер „Кыскача курс“ның VIII нче бүлеген өйрәнәләр. Башлангыч оешма комсомолецларның партия тарихын ничек өйрәнүләре турындагы мәсьәләне гомуми җыелышларга куеп тикшерә. Аерым иптәшләрнең үз эшләрендә ничек эшләүләрен күзәтеп бара.

Мондый үрнәкләрне, комсомолның Кәминкә авылындагы һәм башка колхозлардагы башлангыч оешмалар мисалендә дә күрсәтергә мөмкин. Ләкин бу әле райондагы барлык башлангыч оешмалар да һәм барлык комсомолецлар да партия тарихын өйрәнү буенча шулай яхшы эшлиләр, дигән сүз түгел. Районда комсомолецларның политик белем алуларын оештырмаучы оешмалар һәм үзенең белемен күтәрү өстендә эшләмәүче комсомолецлар да шактый күп. Мәсәлән, Котыш авылы комсомолецлары Климин һәм Сыскин иптәшләр әлегә кадәр „Кыскача курс“ның беренче бүлеген генә өйрәнәләр, ә „Красный Октябрь“ колхозыннан комсомолец иптәш Миронов партия тарихын өйрәнә дә башламаган. Мондый иптәшләр башка оешмаларда да бар.

Югарыда китерелгән фактлар районда комсомолецларның үзлекләреннән партия тарихын өйрәнүләрен оештыру эшенә җитәкчелекнең әле йомшак булуын күрсәтәләр.

ВЛКСМ ның Беренче Май райкомы, аерым алганда аның пропаганда бүлеге комсомолецларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү эшенә игтибарын тагын да көчәйтергә тиеш. Большевиклар партиясенең героик тарихын өйрәнү өстендә барлык комсомолецларның да тырышып эшләүләренә ирешергә кирәк.

Шәрипов.

ФИНАНС-КАССА ДИСЦИПЛИНАСЫН НЫГЫТЫЙК

Илебезнең финанс хуҗалыгын нығыту, дәүләт банкларына акча керемен арттыру, хуҗалык расходларын киметү һәм хезмәт хакы фондын контрольләү эшенә партия һәм хөкүмәт тарафыннан гаять зур әһәмият бирелә. Бу эштә финанс-банк работникларына һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләре өстенә гаять зур бурычлар йөкләнә.

Ләкин кайбер учреждение һәм предприятие җитәкчеләренең эш нәтиҗәләре бу өлкәдә җитди кимчелекләр булуы, хәтта дәүләт дисциплинасын тупас рәвештә бозу фактларына юл куелуы турында сөйлиләр. Казан шәһәре предприятиеләрендә үткәрелгән тикшерү материаллары күп кенә җитешсезлекләрне һәм финанс работникларының касса дисциплинасын бозу фактларын ачты. Мәсәлән, үзләренең сәүдә челтәре булган промартельләр көндәлек акча кеременең 97 процентын шул көнне үк дәүләт банкысы кассасына тапшырырга тиешләр. Ә „Красный Дорожник“ артеле февраль аенда акча кеременең 57 процентын, „Азат Хатын“ артеле 48 процентын гына тапшырганнар. „Татгармоника“ артеле январь аенда акча кеременең бер тиенен дә банкка тапшырмаган. Бу артельләрнең җитәкчеләре партия һәм хөкүмәт карарын тупас рәвештә бозып, үзләренең акча керемнәрен дәүләт банкысыннан яшрен рәвештә төрле хуҗалык расходларына тоту юлына басканнар.

Бу җитешсезлекләр „Ремонтобувь“, „Татгармоника“, „Точмех“ артельләрендә хәзерге көндә дә кабатлана. „Татгармоника“ артелендә касса операцияләре үз вакытында касса кнәгәләренә язылмыйлар. Бу хәл кассадагы акча калдыкларын тикшерүгә комачаулый. Татпромсовет һәм промсоюзларның финанс, контроль-ревизия аппаратлары промкооперация хуҗалыкларында финанс эшен тәртипкә салу мәсьәләсе белән бик начар шөгылләнәләр.

„Спартак“ комбинаты, Росснабторгның баш заготпункты, Росглавкожның Татарстан базасы, Татарстан Урман Промышленносте Халык Комиссариаты һәм башка күп кенә оешмаларда да финанс-касса дисциплинасын бозу, банк контроленнән баш тарту фактлары бар.

Росглавкож директоры Федоров, баш бухгалтер Рәхмәтуллин иптәшләр февраль аенда товар хәзерләү өчен банк кассасыннан 44 мең сум акча алып, аның бары 25 мең сумын гына тиешле урынга тотканнар. Калган акчаның 6 мең сумын командировкаларга, 19 мең сумын икенче чиратта торган башка расходларга тотканнар. Росснабторгның Заготпункт управляющие Назаров, баш бухгалтер Смеловский иптәшләр февраль аенда гына да дәүләт банкысын читләтеп, төрле районнарга 63 мең сумга якын акча переводы ясаганнар. Алар дәүләт банкысында үзләренең ярым счетлары булган Чистай, Арча, Октябрь районнарына да акчаны почта аркылы җибәреп ятканнар.

Почта аркылы ясалган переводларның контрольсезлегеннән файдаланып, „Спартак“ комбинаты җитәкчеләре (директоры Ситников һәм баш бухгалтер Михельсон иптәшләр) күп кенә шәһәрләрдә бер дә кирәкмәгәнгә төрле уполномоченныйлар тоталар. Бу уполномоченныйлар банк контроленнән читтә яшиләр һәм почта аркылы февраль аенда гына да 108,9 мең сумлык перевод алганнар. Комбинатның финанс бүлеге җитәкчеләре перевод операцияләрен шул кадәр киңәйтеп җибәргәннәр, хәтта алар, Казанда торучы кайбер клиентларга да акчаны почта аркылы җибәрәләр.

Татарстан Урман Промышленносте Халык Комиссариатының план бүлеге начальнигы Кондратьев, баш бухгалтер Донских, хезмәт буенча экономист Кириллова иптәшләр ялган документлар белән хезмәт хакы фонды буенча артык акча алып, сверхурочный һәм аккордный эшләргә, файдаланылмаган ял көннәре һәм башкалар өчен түләп килгәннәр. 1939 нчы елның дүртенче кварталында хезмәт хакы фондын Наркоматның Октябрь леспромхозы 181 мең сум, Тельман леспромхозы 171 мең сум, Ширәмәт леспромхозы 189 мең сум, Шәмәрдән леспромхозы 238 мең сум артык тотканнар. Шулай булуга карамастан, бу леспромхозлардан өстәмә хезмәт хакы фондлары сорап көн саен диярлек телеграммалар килеп тора. Ләкин наркомат җитәкчеләре шушы көнгә кадәр бу зур җитешсезлекләрнең сәбәпләре белән кызыксынганнары һәм аны төзәтү чараларына керешкәннәре юк әле.

Шушы рәвешле дәүләт-касса дисциплинасын бозулар аркасында әйләнештәге акча сумаларының күп өлеше банк кассасына керми кала. Бу хәл үз чиратында банк кассасында акча җитешмәүне китереп чыгара.

Партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары, хуҗалык органнары җитәкчеләре дәүләт-финанс дисциплинасын бозуларга каршы аяусыз көрәш алып барырга, бу эштә дәүләт банкысы работникларына һәр яклап булышлык күрсәтергә тиешләр.

А. Сабитов.

Дәүләт банкысы конторасының баш инспекторы.

ТЕОРЕТИК БЕСЕДА НӘРСӘ КҮРСӘТТЕ

ВКП(б) ның Минзәлә райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге марксизм-ленинизм теориясен үзлегеннән өйрәнүче коммунистлар белән күп тапкырлар индивидуаль беседалар уздырды. Бу беседалар, бер яктан аерым коммунистларның үз эшләрендә ничек эшләүләрен тикшереп баруны күздә тотсалар, икенче яктан китап өстендә үзлегеннән эшләүче иптәшләргә бик күп мәсьәләләрне аңларга һәм ачыкларга да ярдәм итәләр.

Безнең районда үзенең политик һәм теоретик белем дәрәҗәсен күтәрүгә чын мәгънәсе белән коммунистларча караучы, большевизм теориясен үзләштерү өстендә системалы рәвештә тырышып эшләүче иптәшләр күп кенә. Мәсәлән, район җир бүлегенең өлкән агрономы Ершов, ВЛКСМ райкомының пропаганда бүлеге мөдире Заһидуллин иптәшләр „Кыскача курс“ның 12 бүлеген дә өйрәнеп конспект төзеделәр. Хәзер марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен өйрәнәләр. Әхметов, Әхмәтҗанов, Меркурьев, Камалиев, Маликов, Шаронов, Измайлов, Моратов, Газизов һәм Мифтахов иптәшләр дә үз эшләрендә тырышып эшлиләр.

Ләкин башлангыч партоешмаларның күпчелегендә теоретик беседаларның көндәлек эш практикасына кергәне юк әле. Башлангыч партоешмаларның секретарьлары, хәтта райкомның кайбер җитәкче работниклары да әлегә кадәр иптәшләрчә теоретик беседаларның әһәмиятен аңлап җиткермәгәннәр. Бу иптәшләр партия пропагандасына җитәкчелек итү бары тик райкомның пропаганда һәм агитация бүлегенең генә эше дип карыйлар. Шул ук вакытта алар үзләренең теоретик белем дәрәҗәләрен күтәрү өстендә дә эшләмиләр. Шуңа күрә дә, мондый иптәшләрнең үз оешмаларында партия пропагандасы эшенә тиешенчә җитәкчелек итүгә һәм коммунистлар белән теоретик темаларга беседалар үткәрүгә көчләре җитми.

Күптән түгел районның җитәкче работниклары белән уздырылган теоретик беседа моны бик ачык күрсәтте. Райком секретареның хуҗалык эшләре турында доклад өчен, яки бюрода каралырга тиешле материалларны тикшерү өчен түгел, бәлки теоретик беседага чакыруы кайбер җитәкче работникларга көтелмәгән нәрсә булып күренде.

Минзәлә Шәһәр Советы башкарма комитетындагы башлангыч партоешма секретаре иптәш Панков „Кыскача курс“ның IV нче бүлеген өйрәнгәндә бик күп мәсьәләләрне ялгыш аңлаган. Беседа вактында аның бу ялгышлары төзәтелде һәм Лениннең „Материализм һәм эмпериокритицизм“ дигән әсәрен укырга тәкъдим ителде. Иптәш Панковка, диалектик һәм тарихи материализмны ныклап өйрәнергә кирәклек, гомумән теорияне өйрәнүдә башкаларга үрнәк булырлык итеп эшләргә кирәклек күрсәтелде.

Район саклык кассасы мөдире, райком пленумы члены Мөхәметшин, Мельуправлениедән Иргалин иптәшләр әлегә кадәр үзләренең вакытларын дөрес бүлә белмәүләреннән зарлануда дәвам итәләр. Партия тарихын өйрәнү өчен вакыт тапмыйлар. Укырга теләгәндә аларга мөмкинлек бар. Бу иптәшләр икесе дә район үзәгендә торалар. Шулай булгач, билгеле сәгатьләрдә райпарткабинетка гына барырга кирәк иде. Ләкин алар бу мөмкинлектән дә файдалана белмиләр. Иптәш Мөхәметшин әле „Кыскача курс“ ның II нче бүлеген генә өйрәнә. Ә ул секретарь булган оешмадагы күп кенә иптәшләр инде берничә бүлеккә аннан узып киткәннәр. Башлангыч партоешма секретаре иптәш Краснов белән дә шундый ук хәл. Ул да, әлегә кадәр, „Кыскача курс“ның II нче бүлеген генә өйрәнә. Ә бу оешмада инде ВКП(б) тарихын XII бүлек буенча да өйрәнүне тәмамлаган иптәшләр дә бар. Шулай булгач, оешмадагы коммунистларның марксизм-ленинизм нигезләрен үзләштерүләре ни дәрәҗәдә икәнлекне тикшерергә, әлбәттә, бу иптәшләрнең көчләре җитмәячәк.

Мондый иптәшләр, партия пропагандасына җитәкчелек итү секретарьларның һәм бюро членнарының эше түгел, аның белән пропагандист шөгылләнергә тиеш, дип уйлыйлар. Бу дөрес караш түгел. Киресенчә, барыннан да элек партоешма секретарьлары үзләре марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә оешмадагы коммунистларга үрнәк күрсәтергә тиешләр. Бу бурычны башлангыч партоешма секретаре иптәш Нянякин дөрес аңлаган. Ул партия тарихын тирәнтен өйрәнә, ярдәмче материаллар укый, консультацияләргә йөри һәм системалы рәвештә лекцияләр тыңлый. Партия, совет һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләре һәм гомумән партактив өчен районда оештырылган „Ял көне университеты“на иптәш Нянякин беренчеләрнең берсе булып йөри башлады һәм бу „университетка“ үз оешмасындагы җитәкче работникларның да йөрүләренә иреште. Иптәш Нянякин, башлангыч партоешма секретаре буларак, үз оешмасында регуляр рәвештә теоретик беседалар оештыра һәм аларга үзе җитәкчелек итә.

Ләкин башлангыч оешма секретарьларының барсы да пропаганда эшенә иптәш Нянякин кебек җитәкчелек итмиләр әле. Безнең районда, үз өстендә эшләргә теләмәүче коммунистлардан партия уставын тайпылышсыз үтәүне партия дисциплинасының бөтен катылыгы белән таләп итәсе урында, андый кешеләргә карата иске төшерү һәм очсыз-кырыйсыз өндәүләр белән шөгылләнү күп урын алган. Мәсәлән, РАЙФО мөдире Камалов, Воровский исемендәге совхоз директоры Давиденко, Минзәлә МТС ы директоры Талипов, район советы башкарма комитетының сәүдә бүлеге мөдире Ситдиков иптәшләр үзләре үк „иске төшерү һәм өндәүләргә без күндек инде“ диләр. Ә теоретик беседаларда исә, партия тарихы буенча бирелгән бик гади сорауларга да ачык җавап бирә алмыйлар.

Яки менә район халык судьясе иптәш Кашафеттиновны алыйк. Аның сүзләренә караганда, ул партия тарихын тулысынча һәм яхшы белә. Ләкин аерым мәсьәләләрне алып конкрет рәвештә тикшерә башлагач, иптәш Кашафеттиновның үз өстендә эшләүгә игтибарсыз каравы күренде. Ул, РСДРП ның III нче съездында меньшевиклар катнашканмы, юкмы икәнлекне белмәде. Билгеле булганча, бу съездда меньшевиклар булмадылар. Бу хәлне иптәш Кашафеттиновның уңае туры килгәндә нинди дә булса алдан өйрәнелгән цитаталар белән ялтырап, үзенең идея-политик белем дәрәҗәсенең түбәнлеген каплап калырга маташуы белән генә аңлатырга мөмкин.

Кайбер иптәшләр, үз эшләрендә эшләргә теләмәүләрен „эш күплек“, „вакыт юклык“ белән капларга маташалар. Райуполнаркомзаг Коробов, райпотребсоюз председателе Зарипов һәм МТС ның өлкән агрономы Иксанов иптәшләрне шундыйлар рәтенә кертергә кирәк. Алар, әлегә кадәр „Кыскача курс“ ның I—II бүлегеннән уза алмаганнар. Бу гүзәл китап чыкканнан соң узган көннәрнең һәрберсендә берәр генә бит укыганда да, бу иптәшләр күптән инде һәм хәтта тирәнтен өйрәнгәндә дә, „Кыскача курс“ ны өйрәнеп бетергән булырлар иде. Шулай булгач эш күплектән, вакыт юклыктан зарланырга урын калмый. Андый буш лыгырдаулар күптән инде тормыш тарафыннан юкка чыгарылдылар.

Күп кенә партоешмаларның җитәкчеләре, индивидуаль беседалар юлы белән коммунистларның идея дәрәҗәләрен чын-чынлап тикшерәсе урында, теге яки бу коммунистның ничәнче бүлекне укуы, кайсы бүлекләргә конспект төзүе яки төземәве турында кирәксез, формаль сводкалар җыю белән шөгылләнәләр. Укылган лекцияләр, уздырылган консультацияләр турындагы статистик саннар гына хәзер инде бер кемне дә канәгатьләндерә алмыйлар. Хәзер коммунистлар лекцияләрнең һәм консультацияләрнең югары сыйфатлы булуын, аларның теоретик яктан тирән эчтәлекле һәм шул ук вакытта ачык аңлаешлы булуын да таләп итәләр. Алар революцион теориянең иң катлаулы мәсьәләләренә җавап бирүне таләп итәләр. Хәзер, үзлегеннән политик белем алу өстендә эшләүче коммунистларга индивидуаль рәвештә һәм квалификацияле ярдәм итү таләп ителә.

Партия пропагандасы эшенә, үзлегеннән политик белем алу эшенә чын җитәкчелекне тәэмин итү өчен, коммунистларның идея-политик яктан ничек үсүләрен, аларның үз эшләрендә ничек эшләүләрен һәм ничек укуларын белеп торырга кирәк. Ә индивидуаль беседалар, әгәр алар системалы рәвештә алып барылсалар, бу эштә гаять зур роль уйныйлар һәм гомумән район күләмендә пропаганда эшен тиешле баскычка күтәрүгә чиксез зур ярдәм итәләр.

Мондый беседалар райком секретарена, шулай ук башлангыч партоешма секретарена да, җитәкче работникларның, совет һәм хуҗалык работникларының теоретик белемнәре һәм политик чыныкканлыклары ни дәрәҗәдә икәнлекне белеп торырга ярдәм итәләр. Шул ук вакытта алар, теге яки бу оешмада эшнең ни өчен начар, яки яхшы торуының сәбәпләрен тизрәк ачарга да мөмкинлек бирәләр.

Революцион теорияне бөтен көч һәм энергия белән тырышып өйрәнгән хәлдә, без, коммунистларның үз эшләрендә ничек эшләүләренә ныклы контроль булдырырга, һәрбер большевикка Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның бөек идеяләре белән коралланууда эшлекле ярдәм итәргә тиешбез.

Хәкимҗанов.

ВКП(б) ның Минзәлә райкомы секретаре

УКУЧЫНЫ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ УКЫТУЧЫНЫҢ РОЛЕ

Партия һәм хөкүмәтебез тарафыннан совет мәктәпләре алдына гаять зур һәм җаваплы бурычлар куелды. Совет мәктәбе яш буынны аңлы дисциплиналы, культуралы, коммунизм төзү өчен батыр көрәшчеләр итеп тәрбияләргә тиеш. Бу бурычны тормышка ашыру педагоглык эшенең нечкәлекләренә төшенеп эшләүне таләп итә.

Мәктәптә аңлы дисциплинаның югары булуы, һич шиксез, өлгерешнең яхшы үрнәкләрен бирүгә китерә. Ләкин мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләренә буйсынмаучы, мәктәптә дисциплинаны бозучы укучылар да юк түгел әле. Мондый балалар безнең 12 нче номерлы урта мәктәптә дә (Казан) бар. Мисаль өчен IV нче „е“ классында укучы Т. ны алыйк. Аның атасы милиция органы эшчесе, коммунист. Анасы йорт хуҗайкасы. Ләкин Т. мәктәптә укытучыларны да һәм өйдә ата-анасын да тыңламый иде. Укытучыларны ихтирам итми, укучыларны җәберли иде. Дәрес вакытында кычкыра-сызгыра, кай вакытларда начар сүзләр дә әйткәли, укытучы тәртипкә чакырса, аңа бармак янауга кадәр барып җитә иде.

Т. белән укытучылар да, мәктәпнең директоры һәм завуч та бик күп тапкырлар беседалар алып бардылар. Ул редколлегия эшенә тартылды, үзе укый торган класснын старостасы итеп сайланды. Ләкин эшләмәде, боларның берсе дә аңа йогынты ясамады, педсоветка чакыруның да тәэсире булмады.

Баланың төзәлүенә өмет беткәч, педсовет аны мәктәптән чыгару турында карар кабул итте. Билгеле, бу җиңел эш, ләкин мәктәптән куылган бала кая бара!

Берничә укытучы белән завуч та Т. ны параллель класска күчереп карау фикере туды. Ләкин мәктәп күләмендә тәртипсезлеге белән билгеле булган баланы бер укытучының да аласы килми. Ләкин IV нче „а“ классында укытучы иптәш Гузаирова бу кыенлыктан курыкмады. Т. ны үз классына алды һәм беренче очрашуда ук бик күптәнге якын танышлар кебек, конкрет эш кушты. Тырнакларны кисеп, чәчне алдырып, бит-кулларны сабын белән юып килергә кушу балага гаҗәп тоелды.

Икенче көнне иртә белән ул бирелгән эшне үтәп килә, яңа иптәшләре арасында беренче көне башлана. Ләкин 3 нче көнне дәрескә килми. Укытучы аның авыруын белгәч, өч укучыны хәл белергә җибәрә. Т. иптәшләрен шатланып каршы ала һәм нинди дәресләр булганны сораша, укытучының өйгә нинди заданиеләр бирүе белән кызыксына.

3—4 көн авырып сәламәтләнгәч дәрескә килә һәм завучтан дәфтәрләр бирүен үтенә. Балада укуга теләк башланганлык сизелә. Иптәш Гузаирова аның кечкенә генә уңышын да күрә һәм аны күрсәтә белә. Дәресне хәзерләп һәм өйгә бирелгән эшне эшләп килүенә аеруча әһәмият бирә, укытучы белән бала арасында дуслык башлана. Т. ның дисциплинасы яхшыра. III нче чиректә күп предметлар буенча яхшы билгесе ала. Укытучы иптәш Гузаирова баланың характерына зур йогынты ясый алды.

Икенче мисаль итеп IV нче „е“ классында укыган В. ны алыйк. Аның да дисциплинасы начар һәм күп предметлар буенча өлгерешө түбән, дәрес калдыра иде. Аңарга карата да югарыда әйтелгән метод кулланылды. В. ның дисциплинасы яхшырды һәм начар билгеләрен бетерде. III нче чиректә аның 8 яхшы билгесе бар һәм бер сәгать тә дәрес калдырмады.

Югарыдагы фактлар баланы тәрбияләүдә укытучының роле гаять зур икәнлекне ачык күрсәтәләр. Укытучы үз классындагы балаларның һәр кайсына карата аерым алым эзләргә һәм аны таба белергә тиеш. Дисциплинасы йомшак баланы туктаусыз „тәртипсез“ дип атау, һич шиксез, аны бозарга мөмкин. Аның аз гына уңышын да күрә белергә, үзенә күрсәтергә, эшкә кушарга, эшләгән эшен җентекләп тикшерергә кирәк.

Кайбер укытучылар дисциплинасы йомшак булган балаларны дәрестән чыгарып җибәрәләр. Бу дөрес түгел, әлбәттә. Баланы дәрес тыңлаудан мәхрүм итмәскә кирәк.

Баланы параллель класска күчерү, билгеле, масса төсен алырга тиеш түгел. Тәртип бозучы балага карата мондый методның һәр вакытта да яхшы нәтиҗә бирмәве мөмкин. Укытучы мәктәп завучы белән берлектә киңәшеп төрле алымнар эзләргә тиеш.

Әхмәт Ишмуратов.

12 нче номерлы урта мәктәп завучы.

ОБОРОНА ЭШЕ ИНИЦИАТОРЫ

Серго Орджоникидзе исемендәге заводта РОКК эше элек бөтенләй диярлек алып барылмады. Бу эш өчен җаваплы кеше юк иде. Заводта эшләүчеләр арасында РОКК эшен оештыру һәм җәелдерү комсомолка иптәш Филаткинага тапшырылды. Ул үзенә йөкләнгән эшне үрнәк рәвештә үтәп, үзен яхшы оештыручы һәм инициатор итеп күрсәтте.

Үткән елның декабрь аенда заводта РОКК ның башлангыч оешмасы оештырылды. Оештыру һәм агитация-масса эшендә яхшы инициатива күрсәткәне өчен РОКК членнары үзләренең гомуми җыелышында комсомолка Филаткина иптәшне комитет составына сайладылар, ә комитет үзенең утырышында аны председатель итеп сайлады.

Иптәш Филаткина РОКК эшенең әһәмиятен бик яхшы аңлый һәм үзенә йөкләнгән бурычларны намус белән үти. Аның инициативасы буенча ГСО түгәрәкләрендә укуга заводта эшләүчеләрдән 168 кеше тартылды. Йөзләрчә кешеләр ГСО значокларына нормалар тапшырдылар. Хәзерге вакытта заводта 6 ГСО түгәрәге эшли. Күптән түгел генә ГСО значкистлары противогазлар белән 5 километр ераклыкка поход ясадылар. Походта 64 кеше катнашты.

А. Овчинников.

МИНЕ КАЙНАП ТОРГАН ЭШ КАРШЫ АЛДЫ

Мин соңгы ике елда үз белгечлегемнән башка эш тармакларында, Москвада эшләдем. Минем кебек производстводан читтә эшләүче күп кенә авыл хуҗалыгы белгечләре үзләренең производствога китеп эшләү теләкләрен матбугат битләрендә күтәреп чыктылар. Бу яхшы теләккә мин дә кушылдым. Татарстанның Калинин районына килеп, өлкән ветврач булып эшли башладым.

Монда мине кайнап торган эш каршы алды. Бу район терлекчелек буенча Татарстанда алдынгы районнарның берсе санала. Ләкин биредә 3 елдан бирле ветврач булмаган. Булган ветеринария фельдшерлары да бик еш алышынып торганнар. Терлекчелек фермаларына ветеринария ярдәме күрсәтү бик аз булган.

Районга килү белән мин ветеринария эшләренең очсыз-кырыйсыз булуын күрдем. Эш күп, бик күп. Аларның һәр кайсы минем иҗад эшемә бәйләнгән. Эшләгән саен эшлисе килә. Иң беренче чиратта без төп игътибарны терлекләр арасында булган авыруларга каршы көрәшкә юнәлдердек. Хәзер бу эшнең кайбер нәтиҗәләрен дә күрергә була. Корчаңгы белән авыручы терлекләр дә бар иде. Моңа каршы көрәштә ветеринария работникларына районның җитәкче оешмалары да нык булышлык күрсәттеләр. Нәтиҗәдә бу терлекләрнең күпчелегендә корчаңгы авыруы бетерелде. Ләкин моның белән тынычланып калырга һич тә урын юк. Терлекләрнең сәламәтлеге өчен өзлексез эшләргә кирәк.

Район җир бүлеге һәм андагы профсоюз оешмасы ветеринария белгечләренә уңайлы эш шартлары тудыру мәсьәләсе белән тиешенчә шөгыльләнмиләр әле. Вактында утын хәзерләнмәү аркасында Пучы ветучасткысының аптекасы ике айдан бирле ягылмый тора. Андагы медикаментлар һәм инструментлар бозылып эшкә яраксыз хәлгә килгәннәр. Үземнең әле һаман да уңайлы квартира белән тәэмин ителгәнем юк. Ветеринария пункты янындагы квартираларда бу эшкә һич бәйләнеше булмаган кешеләр торалар.

Хәзерге вакытта районда ике ветврач, ике ветфельдшер җитешми. Бу турыда Татнаркомземга берничә тапкыр хәбәр итсәк тә ул әле һаман да урыннардан килгән сорауларга колак салмавында дәвам итә. Җавап та бирми, кеше дә җибәрми.

Бу җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерүдә район оешмалары һәм Татнаркомзем җитәкчеләре ашыгыч чаралар күрерләр дип уйлыйм.

Ветврач *Рәшит Җәләлев.*

Аяк киемнәре эшли торган „Ширпотреб“ артеленең алдынгы стахановчы—фрезеровщигы иптәш С. Закиров. Ул беренче квартал планын 200 процент үтәде.

И. Галиев фотосы.

КОРЫ СӨТ

Үзенең тышкы һәм эчке күренеше белән медицина учреждениесен хәтерләткән завод цехларында йөрибез... Мондагы чисталык безне чиксез сокландыра. Заводның баш инженеры иптәш Лозовый безне эш процессы белән таныштыра.

Менә, сөт кабул итү цехы. Сөт саклау өчен хәзерләнгән махсус ванналар сөт белән тулы. Моннан сөт махсус трубалар аша кайнату аппаратларына килә. 85—87 градус эсселектә кайнату процессы башлана. Шуннан соң кайнатылган сөт фильтр аша вокум аппаратка бирелә. Монда кайнатылып куертыла һәм судан арындырыла. Куертылган сөт вокум аппаратларыннан ванналарга салына, ә сөттән аерып алынган су вокум насослары ярдәме белән тышка чыгарыла. Шуннан соң куертылган сөт ванналардан махсус эшләнгән насослар аркылы киптерү башнясенә килә. Монда ул минутына 7—8 мең әйләнеш бирүче пар турбинасы дискалары көче белән вак сөт томанына әйләндерелә. Хасил булган сөт тузаны башнядәге кайнар һава ярдәме белән киптерелә. Тузан хәленә китерелгән коры сөт башня төбенә төшә. Моннан ул махсус приборлар белән иләкләргә алына. Коры сөт әнә шулай эшләнә.

⁂

Алексеевский авылындагы бу завод хәзер Союз күләмендә әһәмият тотучы, азык промышленностеның эре предприятиеләренең берсе булып әверелде. Сталинчыл бишьеллыклар чәчәге булган бу яш заводның яш һәм бердәм коллективы яңа производствоны җитез үзләштерә. Коллектив үз алдында торган бурычларны намус белән үти.

Заводның производство куәте тәүлегенә 24 тонна продукция эшләп чыгаруга исәпләнгән. Стахановча эшләү методларын киң куллану нәтиҗәсендә, завод коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген туктаусыз күтәрә бара. 1938 нче елда ук инде, көндәлек продукция эшләп чыгару 48—50 тоннага җитә.

Эчке мөмкинлекләрне файдалану исәбенә завод елдан-ел күбрәк продукция бирә. Соңгы вакытларда бу өлкәдә аеруча зур эшләр башкарылды. Заводка быел тулысынча капитальный ремонт үткәрелде. Моңа кадәр тар урын булып килгән пар хуҗалыгы тәртипкә китерелде. Монда өстәмә казан һәм машина куелды. Җиһазларны тулы көчләрендә файдалану өчен рационализаторлык чаралары кулланыла. Бу чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә, вокум аппаратларының һәм шулай ук насосларның эшләп чыгарулары элеккегә караганда 20—25 процентка үсте. Көндәлек продукция эшләп чыгару 60—65 тоннага җиткерелде.

Завод үзе үстергән кадрлары белән урынлы рәвештә мактана. Башта гади эшче булган Дуся Бурлакова, Вихорева, Мария Сидорова, Чермышенцева иптәшләр хәзер катлаулы машиналарда эшлиләр, һәр кайсы икешәр аппаратка хезмәт күрсәтәләр. Нормаларын системалы рәвештә 120—130 процентка җиткереп үтиләр. Кочегарлардан Белкин, Воронин, Куличков иптәшләр икешәр пар казанына хезмәт күрсәтәләр. Алар кочегар ярдәмчесе хезмәтен дә үзләре башкаралар, авариясез эшлиләр. Заводта үскән, тәрбияләнгән мондый кадрларны тагын да күп кенә санарга мөмкин. Завод 5 кешене Башкыртстанга, анда яңа гына эшли башлаган коры сөт заводына җибәрде. Бу яңа заводтан килгән 15 кеше завод цехларында махсус курс үттеләр, катлаулы машиналарда эшләү юлларын өйрәнделәр.

Завод коллективы ярты еллык планны орденлы республикабызның XX еллык бәйрәменә үтәү өчен бердәм рәвештә көрәшә. Җәйге сезонга тулы хәзерлекне тәэмин итте. Җәйге сезонда эш 3 сменалы итеп оештырылачак.

Ләкин менә район һәм өлкә оешмалары заводка тиешле ярдәмне күрсәтеп җиткермиләр. Заводны утын һәм автопарк өчен соралган запас частьләр белән өзлексез тәэмин итү мәсьәләләре әле дә булса хәл ителмәгән. Бу тоткарлыклар бетерелгәндә, завод тагын да яхшырак эшләр иде.

Ким Биков.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

Ярышып эшләү яхшы нәтиҗәләр бирә

Татпромсоветның „Большевик“ артеле (Зеленодольски) коллективы 1 нче Майны һәм республикабызның XX еллыгын яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшә. Цехлар һәм бригадалар арасында социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелә һәм договорлар яңартып төзелә. Хәзер артельдә эшләүчеләрдән 110 кеше үзара ярышып эшли.

Артель 1940 нчы елның 1 нче квартал планын 113 процент итеп үтәде. Күпчелек цехлар квартал планын 121—125 процент итеп үтәделәр. Артельнең күп кенә стахановчылары норманы 2—3 тапкыр арттырып үтиләр. Тегү цехы стахановчысы иптәш Косигин аеруча яхшы эшли. Ул көнлек норманы 250—270 процент итеп үти һәм үзенең яхшы эш тәҗрибәләрен башкалар белән уртаклаша. Иптәш Косигин беренче квартал планын 274 процент үтәде. Лукоянова, Хәйруллина һәм Алексеева иптәшләр норманы 121—202 процент итеп үтиләр һәм яхшы сыйфатлы продукция җитештерәләр.

С. Харасова.

Яңа йөкләмәләр алалар

Бондюг заводы коллективы Татарстанның XX еллыгын лаеклы каршылау өчен зур хәзерлек алып бара. Бу уңай белән заводның барлык цехларында һәм бүлекләрендә социалистик ярыш договорлары яңартып төзелде.

15 нче номерлы цех коллективы ярты еллык планны 25 нче июньгә, 11 нче һәм 6 нчы номерлы цех коллективлары 10 нчы июньгә үтәү һәм продукциянең сыйфатын тагын да яхшырту өчен йөкләмә алдылар.

М. Гайфеттинов.

Рационализаторлар

14 нче трест рационализаторлары һәм уйлап табучылары иҗади эшнең яңа үрнәкләрен күрсәтәләр.

Слесарь иптәш Перетягин токарь станогында агач стаканнар эшләү өчен патрон куллану методын уйлап тапты. Аның бу уйлап табуы киң куллану товарлары җитештерү цехында кул ярдәме белән эшләнә торган продукцияне механизация ярдәме белән башкару мөмкилеген бирә.

4 нче контора мастеры иптәш Рашупкин кыйммәтле такдим бирде. Аның такдиме хезмәт җитештерүчәнлеген 200 процентка күтәрү мөмкинлеген бирә.

Шул ук 4 нче контораның ремонт-механика мастерскоенда болтларны кисү өчен уңайлы шартлар тудырылмаган иде. Слесарь иптәш Ващенко плащекларга яңалыклар кертү турында такдим бирде. Ул моннан тыш тагын кран-укосинаның роликларын автомат көче белән майлау өчен яңалыклар табу мәсьәләсен практик рәвештә хәл итү өстендә эшли.

Инженер иптәш Беговатов тагын да әһәмиятлерәк уйлап табу такдиме ясады. Аның такдиме үзе генә дә 50 мең сум экономия бирә.

Инженер иптәш Васильев известьны сүндерү өчен механикалаштырылган юл эзләп табу буенча файдалы эш алып бара.

Байтак эшчеләрдән һәм инженер-техник работниклардан хезмәтне дөрес оештыру, төзелешнең эшләнү бәясен кимету буенча әһәмиятле такдимнәр керә.

3 нче контора коллективы трестның барлык эшчеләрен социалистик ярышка чакырды. Бу контора уйлап табучылары һәм рационализаторлары 1940 нчы елны 100 мең сумлык экономия бирә торган уйлап табучылык такдимнәре кертү турында йөкләмә алдылар.

14 нче трестның уйлап табучылары һәм рационализаторлары шушы елның 1 нче кварталында барлыгы 30 такдим бирделәр. Бу такдимнәрдән килә торган экономия 100 мең сумга якын исәпләнә.

С. Петров.

Наласаны төзекләндерү

Наласа авыл советы (Арча районы) Татарстанның XX еллыгына юл төзелеше планын 20 нче июньгә үтәү, вак юлларны һәм чишмәләрне төзәтү эшен 10 нчы майга төгәлләү өчен көрәшә. Юл төзү өчен таш һәм агач ташылып куелган.

Укый-яза белмәүче һәм аз укый-яза белүче 296 кешедән 1 нче апрельгә 198 кеше укып чыккан. Калганнары укыйлар. Яңа зур клуб эшләнеп бетеп килә. Аның янында көтепханә өчен бина эшләнеп ята. Көтепханәдә 2 меңнән артык китап бар. Авыл советы һәм колхоз идарәсе урнашкан йортның һәм клубның тирә-ягы рәшәткә белән әйләндереп алыначак. Анда кимендә 100 төп агач утыртылачак.

Колхозда беренче тапкыр буларак физкультура мәйданы хәзерләнә.

М. Н.

КАЗАН ШӘҺӘРЕН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

Шәһәрләрне планлаштыруның Дәүләт институты тарафыннан Казанны планлаштыру буенча төзелгән генераль проэкт хәзер СССР Халык Комиссарлары Советы раславына бирелде. Бу проэктта Казанны төзекләндерүнең барлык төрләре дә түгел, бәлки торак йортлар һәм промышленность предприятиеләре төзелеше өчен территорияләр билгеләү, шәһәрнең үсеш юнәлешен, шәһәр транспортын, урамнар челтәрен билгеләү, зур Волга суы басудан саклану чараларын билгеләү кебек принципиаль мәсьәләләр генә чагылдырыла. Бу проэкт Казан хезмәт ияләренә яхшы билгеле. Чөнки аны җәмагатчелек зур кызыксыну белән тикшергән иде.

Хәзер без генераль план нигезендә шәһәрне төзекләндерү буенча хәрәкәт итү планнарын төзү эшен башлап җибәрдек. Бу планда кварталларның, парк һәм бульварларның, шулай ук урамнарның төгәл чикләре, юнәлешләре һәм күләмнәре билгеләнә. Бу планның бер өлеше булдырылды да инде. Ул үзенең эченә нигездә Молотов районын төзекләндерү мәсьәләләрен ала. Бу районның чикләре итеп көнбатыш һәм көнчыгыштан Куйбышев урамы һәм Казан тимер юлы линияләре, төньяк һәм көньяктан Карл Маркс урамы һәм Кабан күле алынды. Шәһәрнең үзәк районнары белән төньяк районнар арасында транспорт элемтәсен яхшырту, тизләтү буенча монда күп кенә чаралар үткәреләчәк. Бу магистраль трамвайлары сәгатенә 30 километр тизлек белән йөриячәкләр. Шәһәрнең төп проспекты—Свердлов урамы 40 метрга кадәр киңәйтеләчәк. Мондагы бульвар Казан хезмәт ияләренә ял итү өчен иң матур һәм иң уңайлы урын булып әвереләчәк. Тоташтан асфальт белән капланган урам буйлап автобус һәм троллейбус линияләре үтә. Ә трамвай линиясе моннан Островский урамына күчереләчәк.

Академия урамы да шәһәребезнең эре һәм үзәк урамнарының берсе булып әвереләчәк. Бу урам Бойничный овраг аркылы Эсперанто урамы белән тоташачак һәм Кабан күле тирәсе районын культура һәм ял итү паркы белән бәйләячәк. Бу урамнарда да трамвай, автобус һәм троллейбус линияләре үткәреләчәк.

Иң зур һәм матур корылмаларның берсе итеп, Куйбышев урамы аркылы үтә торган һәм Чернышевский урамын Щапов урамы белән тоташтырачак күпер төзелешен күрсәтергә кирәк. Кабан күле тирәләре тиздән бакча-парк булып әвереләчәк. Хәзер шәһәребезнең үзәк районын планлаштыру эшләре башкарыла. Үзәк урамнарның берсе булган Бауман урамын 35—40 метрга киңәйтү күз алдында тотыла.

Яңа Казанны төзү буенча кайбер эшләр башланды инде. Карл Маркс, Эсперанто, Татарстан, Пионер урамнарында салына торган яңа торак йортлар, булакны төзекләндерү, Куйбышев урамында төзелә торган сквер һәм башкалар—болар барсы да яңа Казан чаткылары. Куйбышев гидроузелын ходка җибәрү Казанның йөзен тамырыннан үзгәртәчәк. Пароходлар Казан шәһәренә якын ук киләчәкләр. Шәһәребезнең киләчәге чиксез матур. Ул орденлы республикабызның горур башкаласы булачак.

⁂

Яңа Казан төзелеше мәсьәләләре барлык җәмагатчелек фикерен үзенә туплый һәм хәзерге көндә башкарыла торган барлык төр төзелешләрнең дә шәһәрне төзекләндерү буенча булган генераль план нигезендә алынып барылуын, бер төрле дә тайпылышларга юл куелмавын таләп итә. Планировка дисциплинасы нык сакланырга тиеш.

Ләкин дөресен әйтергә кирәк, кайбер район һәм өлкә оешмалары шәһәрне планлаштыру проэктының үтәлешен тупас рәвештә бозалар. Шәһәрне реконструкцияләү эшен алар хөкүмәт тарафыннан зур сумалар җибәрелгәннән соң гына башларга, кампания рәвешендә алып барырга уйлыйлар, күрәсең. Шуның аркасында, хәзерге көндә үткәрелә торган күп кенә яңа төзелешләр таркау рәвештә, шәһәр читләрендә алып барыла. Ә үзәк урамнарда яшәп килгән ярым җимерек, кечкенә йортлар, склад хуҗалыгы биналары, хәтта конюшнялар дә үз урыннарында калуларында дәвам итәләр. Зур һәм яңа төзелешләрне шәһәр читләрендә түгел, ә тиздән эре үзәк булып әвереләчәк Островский, Университетский кебек әһәмиятле урамнарда, Куйбышев һәм Беренче Май мәйданнарында алып барырга, шәһәр үзәгендә урнашкан кайбер промышленность предприятиеләрен шәһәр читенә күчерү мәсьәләләрен хәл итәргә, барлык капиталь төзелешләрне шәһәрне төзекләндерү буенча төзелгән генераль план нигезендә алып барырга кирәк.

Яңа салынган торак йортларның эчке һәм тышкы оформлениеләренә, архитектура ягыннан бизәлүләренә әле дә булса тиешле игтибар биреп җиткерелми. Мәсәлән, Химия-Технология институтының Карл Маркс урамында салынган яңа йортын алыйк. Бу йортның эксплоатациягә бирелүенә берничә ел үтте инде. Ә шулай да төзелеш барган чордагы чүп-чардан тазартылганы юк. Йорт тирәләрен яшелләндерү, төзекләндерү турында һич кем кайгыртмый. Маяковский урамындагы Мединститут торагы һәм коммунальниклар йорты белән дә шундый ук хәл. Финанс-Экономика институты үзенең уку бинасы төзелешен алдан төзелгән план нигезендә түгел, ә тупас рәвештә бозып алып бара. Йортны архитектура ягыннан бизәү планы әле дә булса расланмаган. Мондый тупаслыкларны бетерергә күптән вакыт инде.

Индивидуаль торак йортлар төзелеше турында аеруча тукталырга кирәк. Бу эш хәзер Казанда массовый төс алды һәм төзелеш эшләре „тизләтелгән“ метод белән алып барыла. Ләкин менә бу эшне планлаштыру мәсьәләсе хәзергәчә хәл ителмәгән. Нәтиҗәдә теләсә кем, теләсә кая йорт сала. Индивидуаль торак йортлар өчен шәһәрне төзекләндерү проэктында билгеләнгән Горка авылы территориясе читләтеп үтелә. Ул гына да түгел, бер кем рөхсәтеннән башка үз белдекләре белән төзүчеләр Аркади бакчасындагы 100 еллык кыйммәтле имән агачларын кисәләр, бакчаның кыйммәтен югалтуга алып баралар. „Чортов угол“ урманы белән дә шундый ук хәл. Контрольсезлек әнә шундый җинаяткә кадәр алып бара. Шуңа карамастан, Горзеленстрой һәм райкомхозлар бу җинаятчелек күрнешләренә каршы көрәшмиләр. Бу кимчелекләр якын арада бетерелмәсә, шәһәрне яшелләндерү өчен никадәр өстәмә средстволар кирәк булачак.

Шәһәрне планлаштыру проэктын тормышка ашыру эше бу өлкәдә тәҗрибәләре булган башка шәһәрләрдән үрнәк алу билгесе астында алып барылырга, орденлы Татарстан республикасы башкаласы—Казан шәһәре Сталин эпохасы таләпләренә җавап бирерлек итеп корылырга тиеш.

Копец

Казан шәһәренең баш архитекторы.

Чит илләрдә

НОРВЕГИЯДӘ СУГЫШ ОПЕРАЦИЯЛӘРЕ

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Диңгез министрлегенең хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең төньяк ярлары буенда хәрәкәт итүче Англия эсминецларының икенче флотилиясе ярдәм алып Нарвик фиордын блокадалаган. Кичә Англиянең „Уорспайт“ линкоры күп санлы эсминецлар ярдәме белән Германиянең мина корылмаларын үтеп, фиордка эчкәре кергән. Англиянең хәрби диңгез көчләре Германиянең фиордта яшеренгән эсминецларына һөҗүм иткәннәр һәм немецләр тарафыннан Нарвикка куелган яр буе батареяләрен атудан туктарга мәҗбүр иткәннәр. Лондонда алынган хәбәрләргә караганда, немецләрнең 7 эсминецы батырылган. Англиянең 3 эсминецы бер кадәр зарарланганнар. Белдерүдә хәзер Англия һәм Германия карабларында үтерелгән һәм яраланган кешеләрнең санын төгәл билгеләргә мөмкин түгеллеге күрсәтелә.

НЬЮ-ЙОРК, 14 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресснын хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең Стокһольмдагы миссиясе вәкиле немецләрнең Тронгеймнан көньякка таба хәрәкәт итүче гаскәрләренең Соернны алганлыкларын һәм Тронгейм-фиордка таба бара торган юлларны үз күзәтүләрендә тотуларын белдергән.

БЕРЛИН, 14 апрель. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Төньяк диңгез өстендә очкан вакытта Германия бомбардировщиклары Англиянең 2 су асты көймәсен батырганнар. 12 нче апрельдә Норвегия ярлары буенда булган һава сугышында англичаннарның 10 самолеты һәлак булган, Германия авиациясе 5 самолетын югалткан.

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Рейтерның хәбәр итүенә караганда, Норвегия ярлары буенда тотып алынган 3 немец тральщигы Англиягә китерелгән.

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Лондонга алынган хәбәрләргә караганда, кичә Англиянең Норвегия өстендә очкан 2 самолеты Германия истребительләренә каршы сугышканнар. Немецләрнең бер самолеты бәреп төшерелгән, икенчесе нык зарарланган.

БЕРЛИН, 14 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Тронгейм районында Германия гаскәрләре каршылыкка очрамыйча алга таба баралар. Яр буе ныгытмаларын оборонага хәзерләү тулысынча тәмам булган.

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең көньяк-көнчыгыш ярлары буенда каты сугышлар бара. Кичә Халденнан 20 километр төньяк-көнчыгыштарак, Швеция чигеннән ерак түгел урында—Швебергга Германиядән яңа частьләр китерелгән. Сарпсборг шәһәренең төньяк өлешендәге урамнарда каты сугышлар бара. Германия гаскәрләре тарафыннан алынган Халден белән Швеция арасында элемтә тукталган. Фредрикстадны Халден белән тоташтыра торган күперне норвегиялеләр шартлатканнар.

СТОКҺОЛЬМ, 14 апрель. (ТАСС). Кичәге маглүматлар нигезендә Швеция газеталары тарафыннан күрсәтелгәнчә Норвегиядәге хәлләр элеккечә үк киеренке килеш калуда дәвам итә. Германия гаскәрләре Швеция чигенә кадәр барып җитә алганнар. Шул ук вакытта алар Халден, Сарпсборг, Фредрикстад шәһәрләрен алганнар. Хәзер Германия гаскәрләре Норвегиянең Конгсвингер шәһәре белән Швециянең Шарлоттенберг шәһәре арасында элемтәне өзәргә тырышалар. Бу юнәлештә Германия гаскәрләре уңышлы һөҗүм итәләр.

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕНЕҢ СВОДКАСЫ

БЕРЛИН, 14 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе иглан иткән сводкада болай диелә:

„Германиянең Нарвикка десант төшерүне саклап торган эсминецлары соңгы көннәрдә Германиянең су асты көймәләре һәм самолетлары ярдәме белән Норвегиягә Англиянең хәрби диңгез көчләренең үтеп керергә маташуларын күп тапкыр кире кактылар. 13 нче апрельдә көндез дошман яңадан көчле атака ясады. Сугышта дошманның ике линкордан, авианосецлардан, крейсерлардан һәм күп санлы эсминецлардан торган эскадрасы катнашты. Дошманның көче артык булуга карамастан, безнең эсминецлар сугышны кабул иттеләр. Бу сугышлар вактында Англиянең „Коссак“ эсминецы янып сайга утырды. „Эскимо“ эсминецы һәм башкалар нык зарарландылар һәм һәлак булганнар булса кирәк. Дошманның гомуми югалтуларын, шулай ук безнең үз югалтуларыбызны әлегә дөрес белеп булмады. Германиянең авыр сугыш караблары Германия гаскәрләре Норвегия портларына төшкән вакытта берничә көн буена Норвегиянең яр буйларында патрульлек иттеләр, 9 нчы апрельдә алар Англиянең авыр сугыш карабларының атакасын кире кага алдылар. Шул вакытта Англиянең „Риноун“ крейсеры зарарланды. Безнең авыр сугыш карабларыбызга зарар килмәде. Тронгеймда, Бергенда, Ставангерда һәм Кристиансундта көн тыныч үтте. Немецләр монда үзләренең оборона корылмаларын киңәйтүне һәм ныгытуны дәвам иттерәләр. Осло районында Германия гаскәрләре төньякка, көнчыгышка һәм көнбатышка хәрәкәтләрен дәвам иттерәләр. Башка пунктлар белән бергә немецләр Сарпсборгны һәм Аскимны алдылар. Хейдстадтменда Норвегия армиясенең 100 офицеры һәм 1.500 солдаты коралларын ташладылар. Дания яр буеның әһәмиятле пунктларында авыр батареяләр куелды. Шетланд атауларыннан төньяктарак Германиянең су асты көймәсе дошманның „Глазгоу“ типындагы крейсерына торпеда җибәрде. Скагеррак бугазында дошманның 3 су асты көймәсе юк ителде. Англия авиациясе 13 нче апрельдә Нарвикка, Ставангерга һәм Бергенга һөҗүм ясады. Һөҗүм вактында Бергенга бомба ташланды. Бомба ташлаудан сугыш объектларына зарар килмәде. Германиянең һава берләшмәләре төрле пунктларда Англиянең хәрби диңгез көчләренә атака ясадылар. Инде хәбәр ителгәнчә, дошманның ике су асты көймәсе бомба тию нәтиҗәсендә юк ителде.

Көнбатыш фронтта Мозель белән Пфальц урманы арасында—кайбер урыннарда артиллериянең һәм удар отрядларның җанлы хәрәкәте. Германиянең ике удар отряды Мерцигдан көньяк-көнбатыштарак дошман позицияләре территориясенә тирәнгә үтеп керде. Немецләр сакчылык постларын юк иттеләр, 4 качу урнын җимерделәр һәм пленнәр алдылар. Саарлаутерннан көньяк-көнбатыштарак Франция территориясендә Германиянең удар отряды дошманны шактый югалтуларга дучар итте һәм пленнәр алды. Цвейбрюкеннан көньяктарак дошманның артиллерия ярдәме белән булган алгы постының чыгышы кире кагылды һәм дошман зур югалтуларга дучар ителде. Югары Рейндә һәм Истейн районында Германиянең разведка отряды Рейнны үтеп, Рейндәге атауларның берсендә дошман постлары урнашкан линияне үтеп чыкты“.

СОЮЗНИКЛАРНЫҢ НОРВЕГИЯГӘ ДЕСАНТ ТӨШЕРҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА „ТАЙМС“ ГАЗЕТАСЫ

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). „Таймс“ газетасының хәрби күзәтүчесе, Норвегиягә союзниклар гаскәрләрен төшерү турындагы хәбәрләрне түземсезлек белән көтүчеләр ихтимал бу операциянең бөтен катлаулылыгын искә алмаганнардыр дип яза. Каршылык күрсәтү булганда десант төшерү—оборонада ятучылар пулеметлар белән генә коралланган булсалар да, бик катлаулы операция. Ләкин дошманның көчләре һәм урнашуы турында бик дөрес маглүматлар булмаганда десант төшерү куркынычлы уен булыр иде һәм аның һәлакәткә китерүе мөмкин. Каршылыкка очрамыйча гаскәрләрне җиңел төшерергә мөмкин булган урынны бары тик тулы һәм бик дөрес информация булганда гына билгеләргә мөмкин. Норвегиядәге хәзерге хәлләр вактында дөрес информация алу бик кыен. Уңыш өчен вакытның хәл иткеч әһәмияте барлыкны Англиянең һәм Франциянең хәрби кешеләре тулысынча аңлыйлар дип ышаныч белән әйтергә мөмкин.

АНГЛИЧАННАР ГЕРМАНИЯ ЯРЛАРЫ БУЕНА МИНАЛАР КУЙГАННАР

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Рейтерның хәбәр итүенә караганда, бүген Балтык диңгезендә һәм аңа керү юлларында миналар куелу турында Англия диңгез министрлегенең белдерүе иглан ителгән. Швециянең территориаль суларына миналар куелмаячак. Миналар куелган урынның чикләре түбәндәге координатлар белән билгеләнә: а) төньяк киңлекнең 57 градус 00 минуты, көнчыгыш озынлыкның 10 градус 26 минуты, в) төньяк киңлекнең 57 градус 00 минуты һәм көнчыгыш озынлыкның 12 градус 24 минуты, с) төньяк киңлекнең 55 градус 30 минуты һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 20 минуты, д) төньяк киңлекнең 55 градус 30 минуты һәм көнчыгыш озынлыкның 21 градус 6 1/2 минуты. Балтык диңгезе районы һәм „а“ пунктын „в“ пункты белән һәм „с“ пунктын „д“ пункты белән тоташтыра торган линияләрдән көньякка таба урнашкан юллар районы миналар куелу уңае белән пароходлар йөрү өчен куркынычлы.

Агентлыкның күрсәтүенә караганда, Англия диңгез министрлегенең белдерүе миналар Германиянең бөтен Балтык буена куелган дигән сүз. Мина куелган яңа урыннар эченә Балтык диңгезенең Мемельдән 12 миль көньяккарак сузыла торган пунктка кадәр төньякка таба булган көньяк өлеше керә (Швециянең территориаль сулары керми). Миналар куелган урын Скагеррак һәм Каттегат бугазларында элек мина куелган урыннар белән тоташа. Зур һәм кече Бельт аркылы һәм аннан ары Балтык диңгезенә таба үтә.

Шулай итеп, куелган миналар Германиянең бөтен яр буен һәм Германия тарафыннан оккупацияләнгән Данияне чолгап алалар.

Дания һәм Норвегия алтынының язмышы

ЛОНДОН, 14 апрель. (ТАСС). Лондонның финанс даирәләрендә Даниянең һәм Норвегиянең алтын запасының шактый өлеше моннан берничә атна элек үк инде чит илләргә җибәрелгән иде дип раслыйлар. Аның зур өлеше яшерен рәвештә Лондонга җибәрелгән һәм Англия банкысы подвалларында саклана. 36 миллион фунт стерлинглык алтын Даниядән һәм Норвегиядән Англиягә самолетларда ташылгандыр дип уйлыйлар. Аның бер өлеше АКШка җибәрелгән. Швеция дә үзенең алтынын чит илләргә җибәрә. Март аенда АКШка Швециянең 16 миллион фунт стерлингдан артыграк алтыны җибәрелгән.

ШВЕЦИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЧАРАЛАРЫ

СТОКҺОЛЬМ, 14 апрель. (ТАСС). Бөтен Көньяк Швециядә иглан ителгән карангыландыру 16 нчы майга кадәр дәвам иттереләчәк. Көнбатыш Швециянең күп кенә яңа районнарында да карангыландыру кертелә.

Хөкүмәт бәяләргә контроль ясау буенча дәүләт комиссиясе билгеләде. Комиссиягә киң хокуклар бирелде. Иртәгәге көннән башлап Стокһольмдә автобуслар хәрәкәте 40 процентка киметелә. Автобуслар хәрәкәте бөтен илдә дә нык киметелә.

Рейно хөкүмәтенең хәле

ПАРИЖ, 14 апрель. (ТАСС). Рейно хөкүмәтен яклаучы газеталар палатаның 11 нче апрельдәге утырышы алдыннан вакыйгаларның хәзерге үсешен искә алып интерпелляцияләрне*) тикшерүне кичектерергә кирәк дип белдергәннәр иде. Сенат утырышы беткәннән соң һәм ул Рейно декларациясен тикшермәгәч, бу газеталар депутатлар палатасының да Рейно декларациясен тыңлау белән чикләнәчәгенә һәм бу мәсьәлә буенча палатада тулысынча бердәмлек булачакка шикләнмәгәннәр иде. Ләкин Рейно декларациясеннән соң палатадагы оппозиция кайбер мәсьәләләрне хәзер үк тикшерүне таләп итте. Аерым алганда „республика федерациясе“ вәкилләре (Луи Марен, Домманж) кайбер эчке политика мәсьәләләрен (барлык мобилизацияләнгәннәр өчен кимендә 30 яштән узганнарга карата махсус льготалар һ. б. турында) хәзер үк тикшерүне таләп иттеләр. Алар палата председателен үз такдимнәрен тавышка куярга мәҗбүр иттеләр. Бер тапкыр тавыш биргәндә хәзер үк фикер алышуларны яклап 293 тавышка каршы 237 тавыш бирелде. Икенче тапкыр тавыш биргәндә хәзер үк фикер алышуларны яклап 259 депутатка каршы 249 депутат тавыш бирде. Бу нәтиҗәләр депутатлар палатасында хөкүмәтнең күпчелеге артык зур түгеллекне күрсәтәләр.

*) Интерпелляция—нинди булса да факт яки эш уңае белән парламентта хөкүмәткә язма рәвештә бирелә торган сорау. Гадәттә бу сорау буенча резолюция кабул ителә. Ред.

Исландиянең бәйсезлек иглан итүе турында „Шефартстиденде“ газетасы

ОСЛО, 13 апрель. (ТАСС). „Шефартстиденде“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Исландия хәзерге хәл шартларында үзен Даниядән бәйсез дип иглан иткән.

Исландия хөкүмәтенең карары

БЕРЛИН, 14 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Исландиянең Даниядәге илчесе үз хөкүмәтенең тапшыруы буенча корольгә (Даниянең короле бер үк вакытта Исландиянең дә короле) һәм Даниянең чит ил эшләре министрлегенә Исландия альтингының (парламентының) карарын тапшырган. Бу карарда, хәзерге хәл Исландия короленә конституция тарафыннан бирелгән властьны тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәгәнлекне искә алып, Исландия альтингы үзенең киләчәктә күрсәтмәләр булганга кадәр Исландия хөкүмәтенә бу властьны тормышка ашыруны тапшырганлыгын белдерә диелә. Аннары бу карарда хәзерге шартларда Дания Исландиянең уния (союз) турындагы договорның 7 нче параграфында күздә тотылганча тышкы мөнәсәбәтләрен тормышка ашыра алмаганлыктан Исландиянең үзенең тышкы политик эшләрен алып баруны үз өстенә алырга карар биргәнлеге әйтелә. Даниянең короле һәм чит ил эшләре министре Исландия илчесенә Исландия карарын табигый чара дип караганлыкларын һәм хәзерге шартларда шуны үткәрергә кирәк дип санаганлыкларын белдереп җавап биргәннәр.

СОҢГЫ СӘГАТТӘ

ГЕРМАНИЯ ГАСКӘРЛӘРЕ ХАЛДЕННЫ АЛГАННАР

БЕРЛИН, 15 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Осло районында хәрәкәт итүче Германия гаскәрләре Халденны алганнар.

НОРВЕГИЯ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ШВЕЦИЯГӘ ЧЫГУЫ

ЛОНДОН, 15 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Стокһольмдә иглан ителгән рәсми белдерү буенча кичә 3 меңләп Норвегия солдаты Корисье һәм Орьенг районында Швеция чиген үтеп чыккан. Норвегия гаскәрләре коралсызландырылганнар һәм интернировать ителгәннәр. Болардан тыш Швециягә зур гына санда Норвегиянең тыныч халкы да чыккан.

АНГЛИЯ САМОЛЕТЛАРЫНЫҢ БЕРГЕНГА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 15 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә кич белән Англия авиациясе Бергенга һөҗүм ясаган. Һөҗүмдә диңгез авиациясенең 15 самолеты катнашкан. Бомбалар ташлау нәтиҗәсендә бер транспортта янгын чыккан. Икенче бер караб баткан. Дошманның бер оча торган көймәсе бәреп төшерелгән. Һөҗүм итүдә катнашкан самолетларның берсе үз базасына кайтмаган.

Забайкалье хәрби округы пограничникларының атлы наряды. Алгы планда: „Сугышчан хезмәтләр өчен“ медале белән бүләкләнгән лейтенант иптәш А. П. Курчев.
М. Рунов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ЛЕНИН КӨННӘРЕ АЛДЫННАН

Владимир Ильич Лениннең тууына 70 ел тулу көненә Татарстанның предприятиеләрендә, уку йортларында, колхозларында киң хәзерлек бара. Казан фабрикаларында һәм заводларында йөзләрчә агитаторлар Владимир Ильичнең тормышы, революцион эше һәм Казанда торган вакыты турында беседалар алып баралар.

„Спартак“ комбинатында, Трампаркта, Швеймехпром артелендә һәм Молотов районының башка предприятиеләрендә докладлар үткәреләчәк. Күп тиражлы газеталар һәм стена газеталары пролетар революция юлбашчысына багышлап махсус номерлар чыгаруга хәзерләнәләр.

Финанс-Экономика, Химия-Технология институтларында, Партия Мәгарифе йортында, Укытучылар йортында Лениннең тормышын һәм революцион эшен чагылдырган документлардан, фото-рәсемнәрдән һәм әдәбияттан күргәзмәләр төзелә.

Казан Дәүләт университетында, студент Владимир Ульянов үзенең занятиеләрен алып барган бүлмәдә (хәзер университетның марксизм-ленинизм кафедрасының уку залында) күргәзмә оештырыла. Агитаторлар университетның студентлары арасында, хезмәткәрләре һәм эшчеләре арасында Ленин турында беседалар алып барачаклар. Университетның фәнни көтепханәсендә Ленингә багышлап зур күргәзмә оештырылды.

В. И. Ленин музей-йортына һәм Владимир Ильичнең Казанда булуы белән багланышлы урыннарга экскурсиячеләрнең килүе соңгы көннәрдә гаять көчәйде. Туризм-экскурсия идарәсе Ленин музей-йортына керү өчен 40 мең данә түләүсез путевка чыгара.

Дингә каршы музейнең лекцияләр залында 22—24 нче апрельдә: „Ленин Казанда“ дигән темага лекцияләр үткәреләчәк.

Мехкомбинат предприятеләрендә агитаторлар Владимир Ильичнең тууына 70 ел тулуга багышлап беседалар һәм кычкырып укулар үткәрәләр.

Кама Тамагы районы предприятиеләрендә һәм колхозларында агитаторлар Владимир Ильич Лениннең тормышы һәм революцион эше турында кычкырып укулар һәм беседалар алып баралар.

ВКП(б) райкомы тарафыннан махсус билгеләнгән 27 агитатор В. И. Лениннең тууына 70 ел тулуга багышлап 22 нче апрельдә колхозларда докладлар ясаячаклар.

Чистайның район парткабинетында, мәктәпләрендә, Укытучылар йортында һәм көтепханәләрендә В. И. Ленин көннәренә хәзерлек алып барыла. Владимир Ильич әсәрләреннән һәм аның тормыш юлын чагылдырган фото-рәсемнәрдән күргәзмәләр һәм витриналар оештырыла.

Буденный районында хезмәт ияләре депутатларының җирле советларына сайлаулар вактында эшләгән агитаторлар бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы һәм остазы В. И. Лениннең тормышы һәм революцион эше турында беседалар һәм докладлар үткәрәләр. Урыннарда агитаторларга практик ярдәм күрсәтү өчен партия райкомы район активыннан 40 кешене билгеләде. Колхозларга китү алдыннан алар өчен инструктив киңәшмә үткәрелде. ВКП(б) райкомының парткабинеты Владимир Ильичнең тормышын һәм революцион эшен чагылдырган материаллардан витрина оештырды. Барлык авылларда да В. И. Лениннең 70 еллыгына багышланган материаллар белән стена газеталары чыгарыла.

В. В. Маяковский истәлекләре

14 нче апрельдә Аксубай колхозчыларыннан, эшчеләреннән һәм хезмәткәрләреннән 475 кеше В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу көненә багышланган кичәгә җыелдылар. ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Перепелица шагыйрьнең иҗады турында доклад ясады.

1928 нче елны Казанда Маяковский белән очрашуы турындагы истәлекләр белән урта мәктәп директоры иптәш Пеньков чыкты. Ул, үзенең „Яхшы“ поэмасын аудитория алдында укыган Маяковскийның бөек образының һич тә онытылмаслык булуы турында сөйләде.

Докладтан соң мәктәп балалары В. В. Маяковскийның күп кенә әсәрләрен укыдылар. Педагогия училищесе хоры Маяковскийның музыкага салынган күп кенә шигырьләрен башкарды.

14 нче апрельдә кич белән Кызыл Армия районы үзәге эшчеләренең, хезмәткәрләренең һәм „Беренче Май“ колхозы членнарының В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга багышланган җыелышы булды. Җыелышта 170 кеше катнашты. Каргалы авылының урта мәктәп укытучысы иптәш Асанов бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗады турында доклад ясады.

(ТатТАСС).

ТАТАР СОВЕТ ЯЗУЧЫСЫ МӘХМҮД МАКСУДНЫҢ ИҖАД КИЧӘСЕ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинеты 13 нче апрельдә татар совет язучысы Мәхмүд Максудның иҗад кичәсен үткәрде.

Татар совет язучылары һәм укучылар—матур әдәбият сөючеләр катнашы белән күңелле генә узган бу кичәне М. Максудның иҗады турында кереш сүз белән Татарстан Совет Язучылары Союзы җаваплы секретаре Муса Җәлил иптәш ачты. Кичәдә кыскача доклад белән чыккан тәнкыйтьче Кашаф Гази иптәш М. Максуд иҗадының татар совет әдәбиятында күренекле урын тотуын, аның әсәрләренең җылы лирика, тирән идеялелек белән сугарылганлыгын, тел һәм художество образлары ягыннан югары булуын күрсәтеп үтте.

— М. Максуд нәсер, художество очеркы өлкәсендә нык танылган мастер. Аның нәсерләре сугышчан рух белән, көчле лирика белән, тирән самимилек белән яңгырап торалар. М. Максудның басылып чыккан 6—7 оригинал китабы бар. Алардан „Беренче Май“, „Канлы божралар“, „Язжыры“, „Беренче чәчәкләр“, „М. Максуд әсәрләре“н күрсәтергә була.

М. Максуд әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү өлкәсендә нык танылган көч. Р. Ролланның М. Максуд тәрҗемәсендә чыккан „Кола Бреньон“ы, А. С. Пушкинның „Дубровский“е, Һенрих Һейненең „Германия“се тәрҗемәдә югары сыйфатлылык үрнәкләре булып торалар.

М. Максуд татар операсын үстерү өстендә дә эшли. Ул атаклы „Фауст“ операсын тәрҗемә итте, халык шагыйре М. Гафури повесте буенча „Кара йөзләр“ либреттосын эшләп бетерде.

М. Максуд Кызыл Армиянең Көнбатыш Белоруссия халкына азатлык илткән героик походына катнашты һәм шул вактында „Кара төнне җиңгән кояш турында“ исемле поэма язды.

Хәзер М. Максуд Беранже шигырьләрен тәрҗемә итү һәм оригинал әсәрләр язу өстендә эшли.

Иҗад кичәсендә чыгып сөйләгән Шәриф Камал, Нәкый Исәнбәт, М. Гали, Г. Кутуй һ. б. иптәшләр М. Максуд әсәрләрен, гомумән аның иҗадының уңай якларын күрсәтү, билгеләү белән бергә, анарга оригинал әсәрләр иҗад итүдә күбрәк активлык, кыюлык теләделәр.

Язучы кичәнең ахрында „Кара йөзләр“ операсы либреттосыннан өзекләр, „Шаярмагыз, атарбыз“ исемле нәсерен укыды.

Кичәнең барышында Татар Дәүләт Опера театры солисты Родионов М. Максуд тәрҗемәсендәге „Фауст“ операсыннан Мефистофель куплетларын һәм серенадасын үтәде, артист Ф. Кавалинский язучының „Бетмәде“ исемле нәсере белән Р. Роллан әсәреннән „Ләтчә“ дигән өзекне укыды.

Кичә матур һәм күңелле үтте.

А. Гомәр.

ЕЛГАЛАРДА

ВОЛГА суы 15 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 50 сантиметр, Югары Ослан янында 9 сантиметр, Саратов янында 67 сантиметр артты. Вязовые, Кама Тамагы, Саратов һәм Сталинград янында боз ага.

КАМА суы Молотов шәһәре янында 11 сантиметр, Сарапуль янында 29 сантиметр, Алабуга янында 14 сантиметр артты. Агыйдел тамагыннан алып Лаешка кадәр боз агуда дәвам итә. Сарапуль янында боз кузгалды.

ВЯТКА елгасында Вятские Поляны һәм Мамадыш янында боз ага.

ОКА елгасының югарыгы өлеше боздан арчылды. Рязань һәм Муром янында көчле рәвештә боз ага.

БЕЛДЕРҮЛӘР

17 апрельдә кич 7 сәгаттә, шулай ук 18 нче апрельдә көндез 11 һәм кич 6 сәгатьләрдә пионерлар йортында (Профсоюз урамы), балаларның үзешчәнлек сәнгате көчләренә шәһәр күләмендә смотр үткәрү дәвам итә.

Билетлар ВЛКСМ райкомнары һәм район мәгариф бүлекләре аркылы таратыла.

— 16 нчы апрель, кич 6 сәгаттә Партия Мәгарифе йортында, шәһәрдәге күп - тиражлы газета редакторларының, редактор урынбасарларының һәм әдәби сотрудникларының семинары үткәрелә. Семинарда—„Диалектик методның төп билгеләре“ дигән темада иптәш Морозов тарафыннан лекция укыла.

ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Яшәп килгән законнар нигезендә, **частный практика эшләре белән шөгыльләнүче барлык медицина работниклары** (врачлар, теш врачлары һәм урта медперсонал) *шушы ел 1 нче майга кадәр,* **Горздравта теркәлү үтәргә һәм частный практика эшләре белән шөгыльләнү өчен рөхсәт язуы алырга тиешләр**

Күрсәтелгән срокта теркәлү үтмәгән медработниклар частный практика эшләре алып бара алмыйлар.

ГОРЗДРАВ.

623—1

Казан шәһәрендәге барлык оешмалар һәм предприятиеләр игтибарына

ТАТМЕТРОВЕС

тимер кисү өчен махсус пресс урнаштырды һәм производство кирәкләре өчен, КИСӘКЛЕ ҺӘМ ТАБАКЛЫ ТИМЕРЛӘРНЕ КИСӘРГӘ **ЗАКАЗЛАР АЛА**

626—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Бүген, 16 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында

ИРЕК

19 нчы апрельдә Зур театр бинасында

ФАУСТ

Кич 8 сәгаттә башлана. Коллектив рәвештә килү өчен 29—14 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 16 нчы апрельдә

КУРКЫНЫЧЛЫ СУД

Иртәгә, 17 нче апрельдә ПРЕМЬЕРА

МЕТЕЛЬ

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

Иртәгә, 17 нче апрельдә

КЫЮ КЫЗЛАР

18 нче апрельдә көндез һәм кич

ТАНЯ

Талоннар белән кертелми. Спектакль кич 8 сәгаттә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген зур программада

ЗУР ЦИРК УЕНЫ

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ

ЯРЫШЫ ДӘВАМ ИТӘ

ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ

Уен кич 8 дә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ГРОЗА
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ЯҢА ЗАМАННАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

КИРӘК:

Казан Дәүләт Педагогия институтына даими эшкә БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ һәм ХИСАПЧЫЛАР. 622—3—1

Казмехкомбинатның 2 нче мех фабрикасына даими эшкә ХИСАПЧЫЛАР, РАСЧЕТЧЫ БУХГАЛТЕРЛАР, ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, ТОКАРЬЛАР, 5—6 нчы РАЗРЯД СЛЕСАРЬЛАР һәм ЦЕХЛАР ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР. Кече Ямашев урамы, 86 (6 нчы маршрут трамвае белән барыла). 633—1

Даими эшкә, ашыгыч рәвештә, БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ, (Трест буенча эшләү өчен), ФИНАНС СЕКТОРЫ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР, АШХАНӘЛӘР ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, БӘЯЛӘР БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ-ПЛАНОВИК, СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, АЗЫК ТОВАРЛАРЫ БУЕНЧА ТОВАР БЕЛГЕЧЕ һәм БОНДАРЬЛЫК ПРОИЗВОДСТВОСЫ ӨЧЕН МӨДИР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Киров районы, Ашханәләр тресты, кадрлар секторы. 616—1

Тарловка санаториенда даими рәвештә эшләү өчен ТУБЕРКУЛЕЗ ВРАЧЫ һәм МЕДСЕСТРА. Шартлары турында белешү өчен адрес: Казан, Комлев урамы, Хезмәт сарае, ВЦСПС ның Ял йортлары һәм Санаторийлар Татарстан идарәсе (28 нче бүлмә). 608—3—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1519. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1450.